

Г. КАМАЛ

Г. КАМАЛ

ТГОСИЗДАТ МАТУР ӘДӘБИЯТ СЕКТОРЫ КАЗАН 1941

Альбомны төзүче: *Габдрахман Камал 11*

Художник *Ш. Мөхәммәтэ1(апов* оформлениесе

Тышлыгы худ. *Б. Алъмеиов* эше

Җаваплы чыгаручысы: *К. Ма/лвеев*

СҮЗ БАШЫ

Үзенең тормышын зур эшчәнлек, нәтиҗәле хезмәт белән уздырган Г. Камалның таланты бик күп тармакларда чәчәк атты, татар культура тарихында онытылмаслык үрнәкләр калдырды. Г. Камалның тормышы һәм иҗаты татарның иҗтимагый фикер үсеше тарихында якты сәхифә булып тора. XX йөз башыннан алып Бөек Октябрь революциясенә чаклы булган озын бер чор эчендә формалашып җимеш биргән һәм аннан соңгы вакытта революцион-демократик традицияләрне үстереп, органик рәвештә социалистик революциягә килеп кушылган һәм аңа хезмәт иткән бу катлаулы иҗат, хәзерге совет җәмәгатьчелегенең культура үсеше өчен кирәкле нәрсә. Татарның иҗтимагый тормыш һәм көрәш тарихын өйрәнүдә моның зур әһәмияте бар.

Мораль яктан бозык булган, фикер зәгыйфлеге һәм бушлыгы белән һәркемнең күзенә ташланып торган, кешелекле хисләрен тупасландырып, югалтып бетергән татар феодаль-буржуалары хөкем сөргән вакытта, аларның патша хөкүмәте белән берләшеп, һәрбер милли прогресска каршы һөҗүм итеп торулары вакытында, Г. Камал кыю рәвештә мәйданга ташлана һәм үзенең классик әсәрләрен тудыра. Ул әсәрләр реаль тормышны чагылдыралар, капитализм чорының «өстен» сыйныфына каршы ук булып юнәләләр, аларның тормыштагы эчке һәм тышкы бозыклыкларын фаш итәләр.

Г. Камал, үзенең шәхси тормышындагы кебек үк, әсәрләрендә дә зур көрәш алып бара һәм ул бу көрәшне тар мәгънәдә аңламый. Көрәшне ул җәдитчеләр белән кадимчеләр арасындагы низаг, тарткалашу төсендә кабул итми; чәй мәҗлесләре катында, урам чатында һәм базар почмакларында, яңа тип мәдрәсәләр, яңа тип семья кору һ. б. шундыйлар турында бәхәс сату, кычкырышу — Г. Камал омтылган көрәш түгел. Мондый тип «көрәшчеләрдән» ул ачы һәм мәсхәрәле итеп көлде генә. Аның көрәше — татар тормышын революцион-демократик карашларда алга җибәрү, культурага китерү өчен булды. Ул, көрәшне семья эчендәге тар көрәштән, иҗтимагый аренага чыгарды, һәм бөтен эшчәнлеген җәмгыятьнең прогрессы өчен җикте. Г. Камал талантының күп тармакларда чәчәк атуы да аның чикләнмәгән көрәшче булуына бәйләнә. Дөрес, без Г. Камалны революционер-большевик көрәшче булды димибез, ул бу дәрәҗәгә күтәрелмәде; деспотизмның төп чыганагына каршы, царизм һәм аның бюрократик черегән строена каршы ачыктан-ачык көрәшкә ташланмады. Ләкин ул үзенең әсәрләре белән феодаль-буржуа калдыкларына каршы объектив рәвештә җимергеч удар ясады; революцион-демократик карашта торып аларны тәнкыйть итте. Шуның белән бергә, «Мәгариф» китапханәсен революцион прокламацияләр таратуда файдалану (бу эш шул вакытта эшләүчеләрнең истәлекләре белән раслана), «Азат халык» газетасында системалы рәвештә, патша чиновникларының, жандармнарның хезмәт изләренә ничек һөҗүм итүләре, еврей погромнары оештырулары турында хәбәрләр урнаштырып килүе — Г. Камал көрәшенең тар бер рамкадан чыгуын, объектив төстә интернационал принципларга хезмәт итү юлыннан үсә баруын күрсәтәләр.

Г. Камалның Россиядәге гомуми политик хәрәкәт белән кызыксынып торуы, рус культурасы, интеллигенциясе белән таныш булуы, социал-демократлар белән, аеруча большевик Хөсәен Ямашев һәм революционер язучы Гафур Коләхметов белән якыннан торып аралашуы — аның дөньяга карашын киңәйтәләр, аны милли чикләнүдән чыгаралар. Менә шуның өчен дә Г. Камалның эшчәнлеге күп тармакларга җәелде һәм ул татар культурасы тарихында зур, күренекле урын алуга ирешге.

Галиәсгар Камал, 1905 нче елдагы буржуаз-демократик революция нәтиҗәсендә кузгатылган бик күп проблемаларны татар җәмәгатьчелеге дөньясында беренче башлап хәл итүче булды. Культура, сәнгать

өлкәсендәге эше татарның иҗтимагый фикерен үстерүдә, аны алга җибәрүдә, тормышка яңалыклар кертүдә чиксез зур иде.

Г. Камалның исеме — татар театрының оешуы белән бәйләнгән. Ул — татар театрының атасы буларак. беренче булып аңа нигез салды. Бу өлкәдә аның эше репертуар хәзерләү белән генә чикләнмәде. Театр өчен иң мөһим булган әсәрләр тудыру өстенә, Г. Камал үзенең артистлык эше белән дә актив катнашты. Татар сәхнәсенең культурасын үстерүдә ул — артист, режиссер, декламатор, гример булып эшләде, дистәләрчә профессиональ артистлар хәзерләде. Хәтта ул үзенең каллиграфистлык осталыгын да шушы эштән башлады: театрның афишаларын үз кулы белән язды.

Г. Камалның исеме — татарда чын мәгънәсендәге классик комедияләр тудыру белән бәйләнгән. Ләкин аның язучылык эше комедия тудыруга гына кайтып калмады. Ул бу эшне киң күләмдәге җәмәгать эше белән бергә алып барды, журналист, редактор сыйфатында да, шагыйрь, памфлетист сыйфатында да көчле әдәби эшчәнлек күрсәтте.

Г. Камалның исеме — хәзерге татар әдәби теленә нигез салу белән дә бәйләнгән. Ул беренче башлап халык телендә яза башлады, әдәби телне практик төстә эшләргә керешге һәм Г. Тукай белән бергәләп аны бик нык үстерде.

Ниһаять, Г. Камалның исеме — каллиграфия, рәссамчылык белән дә бәйләнгән. Ул татар культурасы дөньясында беренче башлаучы каллиграфистлардан, беренче художник-карикатурист. Ул юмор, сатира журналларында, 1907 елларда чыккан кайбер газеталарда шаржлар, карикатуралар бастыра. Аның бу рәссамчылык эше, әлбәттә, татар дөньясында яңа күренеш булды. Революциягә чаклы бу эш руханилар тарафыннан дин исеме белән катгый рәвештә тыела иде; ул көферлек санала иде. Шуңа күрә татар художниклары үстерелмәде, талантлар туа башлау белән үк дин исеменнән сүндерелә бардылар. Г. Камал бу өлкәдә дә кыю рәвештә эшкә тотынды һәм карикатуралар ясауны үзенең төп эшеннән аермады. Билгеле, ул художество академияләрендә махсус хәзерлек һәм практика күргән художник түгел, аның бу тармактагы хезмәте бөтенесе дә аерым кыйммәткә ия булырлык оста һәм пөхтә башкарылмаган, әмма аларның әһәмияте зур, алар үз бурычларын үтәгәннәр, тәнкыйть утын тиешле җиргә юнәлдергәннәр һәм рәссамчылык эшенә нигез салганнар. Г. Камал «Яшен», «Ялт-Йолт» журналларында һәм башка газеталарда 200 дән артыграк карикатура бастырган. Алар Г. Камалның әдәби һәм журналистик хезмәтләренә иллюстрация булып торалар. Шул чордагы иҗтимагый-политик тормышны чагылдыралар, революцион-демократик карашлар нигезендә, барлык төр реакцион күренешләрне фаш итәләр. Бу «Альбом»да урнаштырылган карикатуралар моны ачык раслыйлар һәм алар, шуның белән бергә, Г. Камал иҗатын киң рәвештә өйрәнергә теләүче укучылар, укытучылар, гомумән, совет интеллигенциясе өчен бай материал бирәләр.

Таланты киң тармакларга җәелгән, бөтен иҗат көчен революцион-демократик халык файдасы өчен куйган классик язучы Галиәсгар Камалның тормыш һәм иҗат йөзен яктырту теләге белән шушы «Альбом» чыгарыла. Мондый «Альбом» әле татар әдәбияты дөньясында беренче тапкыр чыгарыла. Рус әдәбиятында да мондый «Альбом» нар күп түгел. Шуңа күрә дә аны мөмкин чаклы тулы һәм хезмәт иясенең кызыксынуларын уятырлык итеп чыгару өчен аеруча зур тырышлык һәм озак эшләү кирәк булды.

«Альбом»ны төзүгә хезмәт куючы иптәшләр байтак читенлекләр каршында калдылар. Бу читенлекләрнең кайберсен хәл итүе дә мөмкин булмады. Мәсәлән, Г. Камалның яшь вакытындагы рәсемнәрен бирү кирәк иде, ләкин алар юк. Аның артистлыгын күрсәтеп, үзе башкарган образларны да бирергә кирәк иде, ләкин алар да рәсемгә алынмаганнар. Бу — төзәтеп булмый торган кимчелек өчен, һич шиксез, шул вакыттагы капитализм тормышы, дини-реакцион тормыш, царизмның милли культураларны кысу политикасы гаепле. Шулар аркасында, татар театры революциягә чаклы хокуксыз хәлдә яшәгән, ул вакыттагы постановкаларның, теге яки бу рольне башкаручы артистларның рәсемнәрен алу турында кайгыртучы булмаган, очраклы рәвештә төшелгән рәсемнәрне саклаучы музей, архив кебек нәрсәләр шулай ук булмаганнар, аерым рәсемнәр төрлечә таралып, югалып беткәннәр. Монда бары элегрәк төшелгән, Г. Камал образларын күрсәтүче рәсемнәрдән, С. Гыйззатуллина-Волжская, Г. Болгарскаяларның рәсемнәрен генә бирә алдык.

Г. Камалның атасы — Галиәкбәр Камалетдиновның да рәсеме юк. Кадим карашлы Галиәкбәр үз гомерендә бер тапкыр да рәсемгә төшмәгән. Ләкин аның рәсемен «Альбом» га бирү кирәк табылды һәм аның улы Г. Камал II истәлеге буенча, художник Б. Альменовтан рәсем эшләтелде.

Г. Камал әсәрләренең сәхнәдә гәүдәләнүенә, теге яки бу образның — типның бирелешенә багышланган бүлек, төбендә Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия Театры һәм артистлары хезмәте аша күрсәтелә. Хәзерге көндә татар совет тамашачыларына таныш булган артист-артисткаларыбызның күбесе Г. Камалның турыдан-туры үз булышлыгы белән иҗат уңышлыгына ирештеләр. Г. Камал биргән классик образларны башкаруда үстеләр һәм үсеп киләләр. Г. Камалның бөтен иҗат гомерен күз алдыннан кичергән, вакыты-вакыты белән бергә эшләгән аның Энесе — артист Габдрахман Камал II — «Альбом» ны төзү эшенә керешкәч, артистлар ана чын күнелдән

булышлык күрсәттеләр. Алар ярдәме белән «Альбом»да Г. Камал образларын мөмкин чаклы тулы итеп бирү юлы ачылды.

Рус әдәбиятындагы «Альбом»нар белән чагыштырып караганда, бу «Альбом» да бер нәрсә бик нык күзгә бәрелеп тора. Ул — художникларның әсәрләргә карата үз хезмәтләре юклык. Революциягә чаклы, гадәт буенча, китаплар рәсемсез чыгарылганнар, хәзерге көндә рәсем белән чыгару тормышка яңа кереп бара әле. Г. Камал биргән типлар художникларның фантазиясе аша гәүдәләндерелмәгәннәр, аның бер генә китабы да иллюстрация белән чыгарылмаган. Бу нәрсәнең кирәклеге «Альбом»ны эшләгәндә аеруча нык сизелде. Алдагы вакытта художниклар татар язучыларының, аеруча классикларның әсәрләренә иллюстрация ясарга, аны үзләренең иҗат программаларына кертергә тиешләр.

«Альбом»ның биографик иллюстрацияләре, сәхнә әсәрләренә караган рәсемнәр, шулай ук драматургның үз карикатуралары — Г. Камалның тормыш һәм иҗатын тулырак аңларга, образларын тирәннәнрәк өйрәнергә һич шиксез ярдәм итәр дип ышанабыз.

Гази Кашшаф.

ГАЛИӘСГАР КАМАЛ

(Драматургның тормыш юлы)

Татарстанның Арча районында (элекке Казан губернасы, Мамадыш өязе, Яңа Чүриле волосте), ике ягы сөзәк кенә таулар арасыннан, киңлеге ике метрдан киң булмаган, Кесмәс исемле бер кечкенә елга ага. Бу су кайбер урыннарда 2 — 3 метр тирәнлектә булса да, күп урыннары 10 — 15 сантиметр тирәнлектән узмый. Вак ташларга бәрелеп, шаулап ага ул елга. Арчага килеп җитәр алдыннан, Казанбаш авылыннан чыга торган Казанка елгасына тоташып ренең исемен югалта торган әнә шул Кесмәс суының - ары башында, тауның ике як битенә урнашкан Сикертән авылы җәелеп ята.

Сикертән авылы — иске авыл, аның тарихы Казан ханлыгына барып тоташа диләр. Бу авылның халкы Казан ханлыгы төзелгән вакытларга кадәр удмуртлар арлар) дан торган. Казан ханлыгы төзелгәч, бу авыл халкы татарлар тәэсиренә бирелеп китеп, ислам линенә күчкәннәр һәм шунпан татар исеме күтәреп киткәннәр (Сикертән авылының картлары бу тарихны бпк ышанып сөйлиләр). Сикертән авылы үзенең зур булуына карамастан, бик ярлы авыл булган. Халыкның көн күрүе авыр: икмәк җитешми. өс-баш начар, шунлыктан Сикертән халкы, көзге эшләр беткәч, Казанның төрле районнарына таралып, авыл саен, йорт саен кереп, итек басып йөри торган булганнар (хәзер дә Сикертән халкы киез итек басуга бик осталар).

Менә шул ярлы Сикертән авылының ярлы крестьяны Камлетдин Җомагыл улының семьясында 1850 нче елда бер ир бала — Галиәкбәр Камалетдинов дөньяга килгән.

Камалетдин агайның ярлы семьясы, елдан-ел үрчегән, ярлылыкка ныклап тамыр җәя барган. Ул үзенең 6 — 7 баласын көч-хәл белән туйдырган, балалар укыту, кеше итү дигән нәрсә аның башына керә алмаган. Хәер, ул вакытта Сикертәндә балаларны укытырлык кеше дә булмаган. Галиәкбәрне мулла хатынына бер кыш йөртеп, әгузе-бисмилла әйтергә, таһәрәт алырга, намаз ниятләргә, әлхәм белән кольһуалла укырга өйрәтеп алганнар. Шуның белән аның укуы чикләнгән. Билгеле, бу уку Галиәкбәр Камалетдиновны укырга да, язарга да өйрәтмәгән. Ул үз гомеренә шул надан килеш кала да.

Тормышның чамадан тыш авыр булуы сәбәпле, балаларны туйдырырга мөмкин булмагач, Камалетдин агай өлкән улы Галиәкбәрне Казанга китереп, эшкә бирергә уйлаган. Камалетдин агай 12 яшьлек Галиәкбәрне, Казаннан 75 километрлар ераклыктагы Сикертән авылыннан, шәһәргә үзе китерә алмаган. Үзенең бер якын туганы белән Галиәкбәрне шәһәргә озаткан.

Галиәкбәр Камалетдиновны Казанга ияртеп алып килгән агай, шәһәрдә базар буйлап, кибет саен кереп, Галиәкбәрне урнаштырырга тырышкан. Ләкин укый-яза белмәгән, сәләмә киемле, чабата кигән, ыштыр ураган Галиәкбәрне кибеткә хезмәткә алучы табылмаган.

Очраган бер кешедән сорашып йөри торгач, Печән базарыннан ерак түгел Захарский урамда (хәзер Насыйри урамы) Шиһап хәзрәт Мәрҗани мәчете белән янәшә йортта торучы Казан купецы саналган, Кушлавыч Мифти дип йөртелгән (Мифтахеттин Вәлишин) бер байга, йорт хезмәтенә малай кирәген әйткәннәр.

Мифти бай, — ярый, баланы сынап карыйк, эшкә ярарлык булса алырбыз. Әйдәгез, минем егетләр янында тамак туйдырып алыгыз, соңыннан сөйләшербез, — дигән.

Мифти бай, Галиәкбәрнең алдына (үзенә аерым) бер табак аш, бер бөтен икмәк куйган да: аша егет, дип, үзе бер читкә китеп карап утыра башлаган. Ике көн юлда ачлы-туклы килгән, тумыштан таза туган Галиәкбәр, оялып, тартынып тормыйча, икмәкне зур телемнәргә кисеп куеп, ярты икмәк белән бер табак ашны тәмамлап куйган,

Бу хәлне күргән Мифти бай, — ярый энем, бу баланы мин эшкә алам, моның кулыннан эш килер, таза малайга ошый, ашаганда колагы селкенә. Ашавы барның эше бар дигәннәр, малай монда калсын, — дигән.

Шулай итеп, тамак ялына ялланып Галиәкбәр Камалетдинов дүрт ел Мифти байда хезмәт иткән. Мифти байның эшләре чыгырыннан чыга башлаган булырга кирәк, дүрт елдан соң бай, Галиәкбәрне икенче бер сәүдәгәр Фәтхулла Мамаевка тапшырган. Фәтхулла бай камчат, кама, төлке мехлары белән Эш кылган. Бүрек һәм тун әйләнәләре эшләткән, шулар белән сәүдә иткән.

Яшь үсмер Галиәкбәргә бу һөнәр бик ошаган, ул дәртләнеп эшкә керешкән һәм тиз арада камчат, кама мастеры булып киткән. Фәтхулла бай Галиәкбәрнең уңганлыгын күреп, аны бик яраткан, үзеннән чит кешегә җибәрәсе килмәгән. Ул аны Галиәкбәр дип атамыйча, якташ дип кенә йөртә икән (Фәтхулла бай Сикертәннән ике километр ераклыктагы Масра авылыныкы булган). Яшь үсмер Галиәкбәр Фәтхулла байда күп еллар хезмәттә калган. Солдатка каралган, аннан котылган. Фәтхулла байның да, Мифти бай кебек, бер заман эше кире китә башлый, ахырда ул мастерлар тота алмаслык хәлгә килеп җитә. Ләкин 23 яшькә җиткән җитез Галиәкбәрне ул урамга чыгарып җибәрмәгән. Күп еллар хезмәт күрсәткән, тырыш, аз сүзле, йөгрек куллы яхшы мастердан аерыласы килмәгән. Аны өйләндереп, үз башына көн күрерлек кеше итәргә уйлаган һәм үзенең энесе Хәбибулла исемле бер кешенең кызын димләгән. Хәбибулла Масра авылының бай крестьяны һәм волостной старшина булып эшли икән. Аның олы кызы Мәүгыйзәне Галиәкбәргә ярәшкәннәр.

1874 нче елны Галиәкбәр Мәүгыйзәгә өйләнгән. Ләкин аны үз янына Казанга алып килә алмаган. Бу вакытта аның квартирасы, көн күрүе өчен йортҗир нәрсәләре, кием-салым һ. б. булмаган. Шуның өстенә тапкан акчасының күп өлешен Сикертән авылына, күп балалы, чиктән тыш ярлы атасына биреп барырга туры килгән. Шунлыктан ул хатыны Мәүгыйзәне Сикертән авылына үзенең ата-анасы янына кайтарып куйган.

Камалетдин агай семьясына күчкәч, старшина кызы Мәүгыйзә өчен караңгы көннәр башланган. Каенана авыру, балалар ваклар, эшкә ярамыйлар, ярлылык чиктән ашкан (сөйләүләренә караганда, су алырга чүмеч тә булмаган), эш күп, ат юк, сыер юк, бөтен семьяга чәй эчәрлек сөт бирә торган бердәнбер кәҗә бар. Икмәк кискән вакытта да, «тукта бусы иртәгә ашарга калсын» дип күп өлешен калдырып килгәннәр. Яхшы тормышта үскән Мәүгыйзә бу хәлләргә гаҗиз була, атасы янына барып та зарлана, елый. Галиәкбәр авылга елына бер генә тапкыр кайта икән. Аның шул сабан туена кайткан вакытларында Мәүгыйзә тагын зарлана, мине монда тотма, үз яныңа Казанга алып кит, дип аптыратып бетерә, тагын елый. Ләкин алар һаман авылдан бөтенләйгә китә алмыйлар. Ниһаять 1876 нчы елда гына Галиәкбәр үзенең хатыны Мәүгыйзәне Казанга күчереп, Фуксов урамыннан (хәзер Галиәсгар Камал урамы) Сувор Хәйрулла йортында квартира алып урнашкан. Матур тормышлары шәһәрдә башлана. Алар икесе кара-каршы утырып, көннәр, кичләр, төннәр буе камчат, кама тегәләр. Үзләренең Казанга килүләренә бик разый булалар һәм үзләрен бәхетле саныйлар. Галиәкбәр үзенең Казанга килүе турында сөйләгәндә, һәрвакыт шулай сөйли торган була: «Бәхетле чебен ат койрыгына ияреп булса да шәһәргә керә».

Алар шулай чүкердәшеп кара-каршы эшләп көн күрәләр. Менә шушы семьяда 1878 нче елда 25 нче декабрь дүшәмбе көн (яңа стиль белән 1879 нчы ел 7 нче январь) бер ир бала дөньяга килә.

Бу балага Галиәсгар исемен бирәләр.

Галиәкбәр Камалетдинов аз сүзле, коры табигатьле, уен-көлке яратмый торган, үз сүзендә нык торучы, үзе ышанган нәрсәсен эшли ала торган, кискен табигатьле бер кеше була. Ул бала сөю, иркәләүләрдән ерак тора. Шулай булса да ир бала туганга бик шатлана. Үзенең бер хәреф тә яза белмәвеннән гаҗиз булганлыктан, Галиәсгарне бар көчен биреп, зур гыйлемле кеше булганга кадәр укытырга карар бирә, һәм үз теләген Мәүгыйзәгә әйтә:

— Сиңа әйтәм, әгәр аллаһе тәгалә озын гомер биреп, кәсепләргә уңыш бирсә, бу баланы мулла булганчы укытырбыз, насыйп булса, югыйсә бу наданлык үзәгемә үтте, укый-яза белсәм мин дә менә болай бөкремне чыгарып, инә белән кое казып утырмас идем, син дә төннәр буе болай җәза чикмәс идең.

Галиәсгар, тулы йөзле, зур башлы, кечкенәлегенә карамастан җидди карашлы бер бала булган.

Ата-анасының иртә таңнан кара төнгә кадәр эш өстендә утырулары, аннан да бигрәк, табигатьләре белән бик үк бала җанлы кеше булмаулары аркасында, Галиәсгаргә иркәләнергә мөмкинлек булмый.

2 — 3 — 4 яшьләрендә, җәй көннәрендә Галиәсгарне анасының туган авылы Масрага әбисе, анасы белән бер туган апалары, абыйлары янына кайтарып куя торган булганнар. Яшь баланы авылга җибәрүнең сәбәбе кечкенә: җәй башлану белән Казан татар кустарьлары Мәкәрҗә ярминкәсенә көн-төн хәзерлек алып барганнар. Аларның бала тәрбиясе белән азапланырга вакытлары булмаган. Ярминкәгә барачак Казан байларының малларын хәзерләп өлгертәселәре, шул ук вакытта эш кызулыктан файдаланып, акча эшләп калырга тырышканнар.

Масра авылы, Сикертән авылы шикелле үк, шул ук Кесмәс суы буена якын җирдә тау битенә утыр-

ган бик матур, шул ук вакытта, бай авыл. Ул авыл Галиәсгар өчен курорт булып хезмәт иткән. Бабасы Хәбибулла старшинаның өч-дүрт сыеры, 40 — 50 баш тавыгы, башка хайваннары була, сөт, май, йомырка чиксез күп, ашау-эчү яхшы. Болар бар да Галиәсгарнең сәламәтлеге өчен күп ярдәм иткәннәр. Җәй — Масрада, кыш — Казанда торып, Галиәсгар 6 яшенә житкәч, аны укытырга уйлаганнар, ләкин кайсы мәдрәсәгә бирү турында Галиәкбәр агай бик күп баш ваткан. Ахырда кайнатасы Хәбибулла старшина, үзләренең авылларына яңа мулла китерелүен һәм яна мулланың бик галим кеше булуын, быел мәдрәсә ачып дәрес бирәчәген сөйләгән (Г. Камалнның әйтүе буенча, бу мулла Казанда Салах хәзрәтнең пишкадәме Исмагыйль исемле кеше булган). Галиәкбәр агай, улы Галиәсгарне Масрага җибәрергә уйлаган һәм Хәбибуллага ияртеп аны Масрага озаткан. Галиәсгар бер кыш Масрада укыган.

Кыш буе укып йөреп, бер хәреф тә танымавын күргәч, Галиәкбәр агай, Галиәсгарне артык Масрага җибәрмәскә, Казанда укытырга булган.

Бу вакытта Галиәкбәр Камалетдиновның квартирасы Тихвинский урамда Мажар Фазлый йортында була (хәзер Тукай урамы 5 нче номерлы йорт). Госмания мәдрәсәсе (бу мәдрәсә, Казанның зур байларыннан Җиһанша Госманов салдырганга, «Мәдрәсәи Госмания» дип йөртелгән) бу квартирага янәшә генә икән һәм шунда Галиәсгарне укырга биргәннәр.

Галиәкбәр Камалетдиновның бер кызык табигате булган. Ул бер квартирада да, бер ел, аша китсә, ике елдан артык тормаган, һаман квартира сайлаган. бер квартирадан икенчесенә күчеп йөргән, шунлыктан Галиәсгаргә, бер ел бер мәдрәсәдә, икенче ел икенче мәдрәсәдә, өченче ел өченчесендә укырга туры килгән. Г. Камалның анасы Мәүгыйзә абыстайның әйтүенчә, шул заманның асламчылык итүче бер карчыгы Магри Бану абыстай: Кара савыт Шаһига хатын ярамый, камчатчы Галиәкбәргә фатир ярамый, дип сөйли торган булган. Шулай итеп Галиәсгаргә Госмания, Халидия (Зәңгәр мәчет мәдрәсәсе). Галләм хәзрәт, Әҗимов, Казаковлар мәдрәсәләрендә укырга туры килә. Ахырында ул Мәдрәсәи Мөхәммәдиягә килеп керә (Г. Баруди мәдрәсәсе. Мөхәммәдиягә килеп кергәч, Галиәсгарнең бөтен тормышы мәдрәсәгә күчә һәм аның өчен бөтенләй икенче бер дөнья ачылып китә. Ул вакытта инде аңа 14—15 яшь була.

Г. Камал мәдрәсәдә хөр фикерле шәкертләр белән таныша. Баштарак Шиһап Мәрҗани, соңга таба Каюм Насыйри әсәрләрен укый. Кичләрендә җәмәгать сәкеләрендә җыелып фикер алышулар башлана.

Галиәсгар Камалда русча уку дәрте кабына. Әтисе дә «адрес язарлык» күләмдә русча укуга каршы тормый. Озакламыйча Галиәсгар Миргаяз Иманаевның «3—х классная городская начальная школа» сына йөри башлый.

Г. Камал, кыш көннәрендә мәдрәсәдә укый, җәй көнендә атасы белән Мәкәрҗә ярминкәсенә бара.

Мәкәрҗәдә Казанның татар кустарьлары Арбеков номерларында торалар. Монда килгән кустарьлар (итекчеләр, читекчеләр, кәләпүшчеләр, бүрекчеләр, тартмачылар һәм башкалар) күбесе семьясы белән киләләр. Алар бөтен семьялары белән көн-төн эшлиләр.

Г. Камал Мәкәрҗәдә Арбеков номерларында түбән катлау халыкның тормышын, аларның буржуа тарафыннан ничек изелүләрен һәм мещан тормышындагы бөтен ваклыкларны аерым-ачык күрә.

Галиәкбәрдә өйрәнчек булып Шаһимулла исемле бер малай эшли. Бу малай бик шат табигатьле, уен-көлке сөйләргә яратучы, йөгрек бер малай була.

Галиәсгар Шаһимулланы үзенә бер якын иптәш итеп ала, үзе кая барырга теләсә, аны үзе белән алып бара, уйный, шаяра.

Мәкәрҗәдә алар, якшәмбе көн көндез Никитин циркына баралар, Арбеков номерларына бик якын булган балаганнарга керәләр, өйрәнгән маймылларны, Һиндстан факирларын, биюләр, фокуслар һ. б. карыйлар.

Шул вакытлардан алып театр, «кәмит», күңел ачу уеннары Галиәсгарнең күңелен кытыклый башлыйлар.

Казанга кайтып, мәдрәсәгә күчеп килгәч, Г. Камал бөтен күңелен театр эшенә бирә башлый. Аның укый торган дәресләре, корьән тәфсирләре, хәезнифас мәсьәләләре, гарәп нәхүләре аңа ят тоела башлый. Ул алардан читкә тайпылырга тырыша, театр әдәбиятын өйрәнә. Якшәмбе көннәрдә Казан шәһәр театрына көндезге спектакльләргә баргалый, сәхнә әсәрләре язу хыялына керешә.

1898 нче елда, 19 яшьлек Галиәсгар беренче әсәрен — «Бәхетсез егет» не яза. Русча укытучысы Миргаяз Иманаевның киңәше буенча әсәрне Петербургка цензурага җибәрә һәм 1899 нчы елда (бер ел үткәч) басарга рөхсәт алып, әсәрне «Брадәран Кәримовлар» басып чыгаралар.

Беренче әсәрнең басылуы Г. Камалның дәртен күтәрә. Ул икенче әсәре булган «Өч бәдбәхет»не шул ук елны бастырып чыгара.

1900 нче елда Г. Камал икенче мәртәбә призывта каралып, солдат хезмәтеннән азат ителә, 2 нче разряд ополчинец булып кала.

Шул көннән башлап Галиәсгарне мулла итү дәгъвасы күтәрелеп китә. Г. Камал мәдрәсәдән чыга. Галиәкбәр агай аны үзе туган авылга, Сикертәнгә, мулла итәргә тырыша. Сикертән малайларының, үзе кебек, халык теле белән әйткәндә, әлифне таяк дип белми калуларын теләми.

Галиәсгар, мин Казанда тудым, анда укыдым, үстем. нигә инде авылга кайтыйм, мин анда кайтмыйм, дип каршылык итә. Аның мулла буласы килми.

Авылга кайтып мулла булырга риза булмагач, аны шәһәрдә мулла итәргә уйлыйлар, ләкин моның өчен зур абруй (авторитет), бай, көчле бер группаны үз янына тупларга кирәк була, төрлечә эзләнүләр китә. Ахырында Казанның зур байларыннан, мех белән сәүдә итүче, Җиңги Садыйк дип йөртелә торган, Садыйк хаҗи Хәйбуллин дигән бер байның, бик үк сәламәт булмаган Гайшә исемле кызына Галиәсгарне зур придан алып өйләндерәләр.

Садыйк хаҗи үз тирәсенә Казанның байларын оештыра, Яңа бистә белән Иске бистә арасына кереп калган иске зират өстенә мәчет салып, шул мәчеткә Галиәсгарне имам, мөдәррис ясарга җыена башлыйлар.

Ләкин яңа әдәбият белән җилкенгән Галиәсгар моңа риза булмый. Ул муллалыктан бөтенләй баш тарта. Аның бу эшеннән аптырап калган атасы һәм кайнатасы гаилә киңәше уздыралар һәм бөтен кардәш-ыруларын җыялар. Киңәшәләр, сөйләшәләр. Ахырда Галиәсгаргә китап кибете ачып бирергә, аны сәүдәгәр ясарга, дигән карар чыгарыла. «Китап кибете» турындагы карарны Г. Камал шатланып каршы ала. Һәм 1901 нче елны «Мәгариф» исемле китап кибете ача. Менә бу кибет инде Г. Камалга үзенең теләкләрен җаелдереп җибәрергә мөмкинлек бирә. Атасы Галиәкбәр белән Садыйк хаҗи бу кибет дин юлында хезмәт итәр, Сөбателгаҗизин, Мөхәммәдия, Иман шарты, коръән тәфсире сатар, дип уйлап торганда, «Мәгариф» китапханәсе бөтенләй икенче юл белән китә. Анда газета-журналлар сатыла, вак әкиятләр, язу-канцелярия нәрсәләре сатыла башлый. Г. Камал үз янына ярдәмгә Казанбашы авылының Габдулла Вәлиев дигән бер егетен ала. Озакламый үзе, «Мәгариф» китапханәсен яңа әсәрләр белән баетуны күздә тотып, Төркиягә китә.

Г. Камал Истамбулга баргач, Төркиянең язучылары, Намыйк Камал шикелле зур әдипләре белән таныша. Алар белән җиңел генә беседалар ясый һәм төрекнең прогрессив карашлы язучыларының әсәрләрен җыйнап, Казанга «Мәгариф» китапханәсенә кайтара, аларны халык һәм шәкертләр арасына тарата башлый.

Шул вакытларда Германиядән полиграфия эшенә өйрәнеп кайткан Мәхмүт Алмаев дигән егет белән очраша һәм алар икәүләп гектографиядә басып «Тәрәккый» исемле яшерен газета чыгара башлыйлар. Бу газета яшерен рәвештә, «Мәгариф» китапханәсе аркылы шәкертләр арасына таратыла.

Г. Камал үзе белемен арттыру эшендә дә дәвам итә. Ярым-ярты аңлап булса да рус газеталары, журналлар, русның зур язучыларының әсәрләрен укый, рус театрына бик еш йөри. Китап сәүдәсе белән Мәкәрҗә ярминкәсенә бара, халык арасына керә, хөр фикерле кешеләр белән очраша, көннән-көн белемен арттыра.

1905 нче ел революциясе килеп җитә. Менә монда инде «Мәгариф» китапханәсенең эше зурая, роле киңәя. Социал-демократлар партиясе чыгарган брошюралар, листовкалар «Мәгариф» китапханәсе аркылы Казанның бөтен мәдрәсәләренә, бигрәк тә. Мөхәммәдия мәдрәсәсенә, тарала башлый.

Беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев. Алафузов заводы эшчесе Вахитовлар «Мәгариф» китапханәсенең хезмәте белән файдаланалар.

Ул заманда шәкертләрне мәдрәсәдән чыгарып йөртмиләр. Шул сәбәпле мәдрәсәгә җибәреләчәк листовкаларны икенче бер кеше аркылы озатырга кирәк була. Галиәсгар бу эш өчен үз энесен файдалана, Аның Мөхәммәдиядә укый торган Габдулла исемле (соңыннан ул мәшһүр артист булды. Г. Камал I исеме белән йөрде) энесе була. Шул Габдулла Казанның бөтен мәдрәсәләрен Ямашевлар тарафыннан чыгарылган листовкалар, брошюралар белән тутырып йөри.

1905 нче елгы революциядән соң, Г. Камал рәсми рәвештә газета чыгару уена төшә.

1906 нчы елда, 1 нче февральдә, Казан муллаларыннан берсе булган Габдулла Апанаев белән бергә Г. Камал «Азат» исемле газета чыгара башлый. Габдулла Апанаев газетаны дин маскасы астында кара груһларга хезмәткә сөйрәсә, Г. Камал «Азат» газетасын сул якка сөйри башлый. Шуның өчен газетаның эчтәлеге капма-каршылыклы булып чыга. Акырып яткан дини мәкаләләр артыннан ук, кызыл фикерле мәкаләләр ярылып яталар. Крылов баснясында арбага җигелгән Аккош, Кыскыч, Чуртан, арбаны өч якка сөйрәгәннәре кебек, «Азат» газетасы да, төрле якка сөйрәлә. Габдулла Апанаев уңга, Г. Камал сулга сөйриләр. Газета бер мәртәбә судка да бирелә, ләкин гаепсез табылып, чыгуында дәвам итә. Ике язучы ике якка сөйрәгән газета озын гомерле була алмый, әлбәттә, 50—60 номерлар чыккач, ул туктый. Г. Камал һәм аның юлдашлары фикере белән килешә алмаган Габдулла мулла Апанаев газетаны ташлап чыга һәм «Казан мөхбире» газетасына язышa башлый.

Габдулла мулла Апанаев китү белән Г. Камал бөтен газетаны үз җаваплылыгына алып, исемен үзгәртеп, «Азат халык» исеме белән чыгара башлый. «Азат халык» газетасы, беренче номерыннан башлап, чын мәгънәсе белән сул фикерле газета була. Бу газетаның эшенә социал-демократлар да катнашалар. Аларның тәэсире белән Думага каршы. «Иттифакый мөслимин» кебек буржуа партияләренә каршы, милләтчеләргә каршы мәкаләләр басыла. Газета буржуазия һәм хөкүмәтнең начарлыкларын фаш итә, халык интересын яклый һәм гомуми халык демократиясе өчен көрәшә. Шуңа күрә газетага цензура һәрвакыт бәйләнеп тора, аерым номерлары бер-ике көн буе язылучыларына таратылмый тора. Ә инде 15 нче номердагы баш мәкаләсе өчен

газета конфисковать ителеп, Галиәсгар Камал судка бирелә. Суд Г. Камалны 1 айга иркеннән мәхрүм итәргә, гражданский гаупт-вахтага ябарга хөкем чыгара. Г. Камал бу карарга каршы апелляция бирә, адвокат яллый. Яңадан суд була һәм арестны 100 сум штраф белән алыштыралар. Г. Камал бу штрафны түләп, ябылудан котылып кала.

Шул ук 1906 нчы елның көзендә югары уку йортларында укучы татар яшьләре, халык өчен ачык спектакль куярга җыеналар. Сәхнәгә куяр өчен төрек классик язучысы, драматург Намыйк Камалның «Зәваллы чуҗык» исемле әсәренең Г. Камал тәрҗемәсе сайлана. Ул әсәр 1900 нче елда «Кызганыч бала» исеме белән басылып чыккан була. Бу әсәргә өстәлеп сәхнәгә кую өчен тагын «Гыйшык бәләсе» исемле комедия дә билгеләнә. Бу спектакльне оештыру эшендә Г. Камал актив катнаша. Аңа үз кулы белән афишалар яза (ул вакытларда афишаларны татарча чыгарырга зур шрифтлар булмаганга, афишалар кулдан тушь белән язылып, литографиядә басыла иде. Шул чорларда чыккан газеталарның исемнәре дә кулдан язылып, клише ясатылып басыла иде). «Мәгариф» китапханәсе аркылы билетларын сата.

Халык өчен ачык спектакльләр куела башлау Г. Камалда драма әсәрләре тудыру дәртен яңадан кузгатып җибәрә. Ул үзенең 1900 нче елда басылып чыккан, техник яктан сәхнәгә куярга яраклы булмаган «Бәхетсез егет» исемле драмасының яңа редакциясен язып тәмамлый, аны «Мәгариф» китапханәсе тарафыннан бастыртып чыгара.

Озакламый ул, үзенең беренче комедиясе — «Беренче театр»ны яза.

1906 нчы елның көзендә «Азат халык» газетасы туктатылгач, Г. Камал, Сәедгәрәй Алкин тарафыннан чыгарыла торган «Казан мөхбире» газетасына кереп эшли башлады. Ләкин озак вакыт эшли алмады. газетаның тоткан юлы белән килешә алмыйны ташлап чыгып, Һади Максуди тарафыннан чыгарыла торган «Йолдыз» газетасына кереп эшли башлады.

1908 нче елны Г. Тукай белән берлектә Г. Камал «Яшен» исемле сатира-юмор журналы чыгарырга керешә. Бу журналның редакциясе Г. Камалның үз квартирасында иде. Журналны чыгаручысы, язучысы һәм художник Г. Камал үзе булды. Төннәр буе утырып журнал өчен карикатуралар ясый иде, ләкин бу журнал озак яши алмады, 10 номер чыккач үз расходын каплый алмыйча тукталып калды.

«Яшен» журналы тукталгач. Г. Камал яңадан «Йолдыз» газетасына эшкә керде. Бу елны инде ул чынлап язу эшенә керешә. «Мәгариф» китапханәсен Рәхим һәм Әмин хәлфәләр, Мостафиннарга ташлап чыкты.

1908 нче елда Г. Камал «Беренче театр»ны бастырып чыгарып, «Бүләк өчен» комедиясе яза башлады һәм аны 1909 нчы елны бастырып чыгарды.

Г. Камал язучы, драматург кына булып калмады, татар театрының атасы булуны да өстенә алды. Габдулла Кариев карамагында «Сәйяр» труппасы төзелгәч, труппага матди һәм мәгънәви ярдәм итте. Труппа һәр елны Мәкәрҗә ярминкәсенә бара, Фо-ле-бирҗер бакчасында, Модерн театрында спектакльләр куя иде. Бу эш өчен рөхсәт алу, билет тарату, театр бинасына гарантия өчен акча табу — Г. Камал өстенә йөкләтелә иде. Г. Камал болар белән генә калмыйча костюмерлык хезмәтен дә үти. Труппаның артистлары төрле җирләрдән, шәкерт-шөкертләрдән, приказчиклардан җыйналган кешеләр, алар чамадан тыш фәкыйр булалар, ашарларына икмәкләре, киярләренә киемнәре булмый. Шулар белән спектакль куярга һәм аның өчен әллә никадәр киемнәр, биш билле казакилар, камзуллар, читек-кәвешләр, җиләннәр, чапаннар, чалмалар һәм башкалар табарга кирәк. Шул нәрсәләрне булдыру өчен Г. Камал артистларны ияртеп Мәкәрҗә буйлап йөри. Казан сәүдәгәрләре, кустарьлары өчен таныш булган камчатчы Галиәкбәр ышанычлы кеше санала. Ә инде аның улы Галиәсгаргә шулай ук ышаналар һәм кием-салым биреп торалар. Бигрәк тә кустарьлар арасында Г. Камалны яхшы беләләр. Чөнки ул алар арасында кайнашып үскән.

Г. Камалны артистлар, эткәй, дип йөртәләр. Аның киңәшләрен тоталар, аны ихтирам итәләр.

Казанда күл буенда Хәйрулла Хәмитов дигән бер байның йортында ачылган Казан татар яшьләренең «Шәрык клубы» 1910 нче елны Евангелистовский урамга (хәзерге Татарстан урамы), Апанаев Кәримнең өч катлы йортына күчә. Анда күчкәч, клуб үзенең эшен Зурайтып җибәрә. Шушы елнЫ «Сәйяр» труппасы кышкы сезонга Шәрык клубына айлыклы жалование белән яллана.

Артистларны яллау эшен Г. Камал белән Гафур Колахметов (бу вакытта алар Шәрык клубының старшиналары булалар) яклап чыгалар һәм труппаның утырак эшенә булышалар.

Шул беренче сезонда Г. Камал «Сәйяр» труппасында режиссерлык итә. Шул ук вакыттан «Сәйяр» труппасында Гөлсем ханым Болгарская да эшли башлый.

Гөлсем ханым Болгарскаяның труппага килеп керүе белән «Сәйяр» труппасы иркен сулыш ала. Гөлсем Болгарская, труппада үзе эшләү белән бергә, якын дусларыннан Зәйнәп, Хәдичә Рәхмәтуллина, Мәрьям Сираҗетдиноваларны һәвәскәр рәвешендә спектакльләргә катнашырга алып килә башлый. Пьесаларда язылган асрау-кызлар, күрше хатын рольләре әсәрдән элеккечә сызылып ташланмыйлар, ирләр белән алмаштырылмыйлар, тулы килеш уйнала башлыйлар.

1910 нчы елда Г. Камал үзенең «Уйнаш» драмасын язып бетерә һәм ул беренче мәртәбә шушы

сезонда Шәрык клубында «Сәйяр» труппасы тарафыннан, Г. Камалның үз режиссерлыгы белән уйнала.

Г. Камал үзенең туган энесе Габдулла Камалны (Камал I) да сәхнәгә тарта. Галиәкбәр агайның ихтыяры белән читек-кәвеш кибетендә приказчик булып йөргән Габдулла Камал, шушы 1910 нчы ел сезонында труппага килеп керә.

1911 нче елда Балкан сугышы башлана.

«Йолдыз» газетасы Г. Камалны Төркиягә үз хәбәрчесе итеп җибәрә. Бу елда Төркиядә каты суыклар һәм бер туктаусыз яңгырлар башлана. Юклыбарлы акча белән киткән Г. Камал Истамбулда бер фәкыйрь төрекнең миче-фәләне булмаган бер чарлагында тора, хәбәрчелек итә. Бер туктаусыз яңгырлар, салкын һава Г. Камалның сәламәтлегенә бик күп зарар китерә. Г. Камал Төркиядән бик каты авырып, кул, аягы эшләмәгән хәлдә әйләнеп кайта.

Г. Камал Казанга кайткач озак вакытлар дәвалана. Казанның иске клиникасында электр ванналары ала. Күп вакытлар үткәч кенә кул, аяклар азрак язылалар. Акрынлап ул йөри башлый. Кулы каләм тотарлык хәлгә килү белән Г. Камал тагы язу эшенә керешә һәм үзенең атаклы комедиясе «Банкрот» ны яза һәм 1912 нче елда аны бастырып чыгара. Шул ук елда «Дәҗҗал» исемле драмасы язылып басыла һәм Шәрык клубында «Сәйяр» труппасы тарафыннан уйнала.

1913 нче елда Г. Камал үзенең зур комедиясе «Безнең шәһәрнең серләре»н яза. Бу комедиядә Г. Камал Печән базары мещаннарының пычрак тормышларын ачып салды. Үзләрен милләтнең алдынгы кешеләре дип йөргән, эшлексез, череп таралган милләтчеләрдән, җәмгыяте хәйрия агзаларыннан ачы сатира белән көлде. «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясе агай-эне арасында, Казан татарлары, Казан муллалары арасында зур шау-шуга сәбәп булды.

«Безнең шәһәрнең серләре» язылып уйналгач, Казан татар буржуасы, муллалары, Печән базары әһелләре Г. Камалга каршы ут ачтылар, хәтта террор оештырдылар. 1913 нче елның көзендә, караңгы, яңгырлы бер төндә, извозчикта утырып кайтып килә торган Г. Камалга Фуксовский (хәзер Г. Камал урамы) һәм Московский (хәзерге Киров урамы) урамнары чатында һөҗүм ясадылар. Һөҗүм ясаучы ике кадаклы гер белән һөҗүм итә, ләкин Г. Камалның башын[а] ук суга алмый, гер Камалның уң яңак сөягенә тия. Ләкин бу һөҗүм Г. Камалның сәламәтлегенә зарар китерә алмады.

Шул ук 1913 нче елда Г. Камал үзенең «Кайнеш» исемле комедиясен бастырып чыгарды.

1913 нче елдан алып Октябрь революциясенә кадәр Г. Камал төбендә тәрҗемә әсәрләр язу белән шөгыльләнде. Ул «Саран», «Хөкемдә хаталык», «Гашыйк», Кибетче кебек әсәрләр өстенә, Островскийның «Гроза»сын, «Гаепсез — гаеплеләр»ен, Габделхак Хәмитнең «Һинд кызы»н, М, Горькийның «На дне» («Тормыш төбендә») сен, Мольерның «Ирексездән табип», «Хаста» һ. б., Н. Гогольнең «Ревизор»ын, Лопе-де-Веганың «Сарык чишмәсе»н һ. б. тәрҗемә итте.

Г. Камал 1917 нче ел Февраль революциясеннән алып Октябрь революциясенә кадәр күзгә чагылырлык эш эшләмәде дисәк тә ярый. Ул бу арада төрекнең зур әдибе Габделхак Хәмитнең «Ватан» исемле әсәрен һәм «Эшчеләр бистәсе» исемле пьесаны тәрҗемә итте.

Бөек Октябрь революциясе булу белән Г. Камал һич икеләнеп тормастан, большевиклар юлыннан китте.

Большевиклар партиясе органы булган газеталарда эшләде, шигырь, декламация һәм ораторияләр язды.

Мулланур Вахитов җитәкчелегендә булган Мөселман социалистлар комитеты янына яшьләрне җыйнады, драма түгәрәге оештырып режиссерлык итте, түгәрәкнең җитәкчесе булды. 1918 нче елда Казанга чехлар килгәндә, Г. Камал Казаннан 9 километр җирдә Аракчино авылында дачада тора иде. Ул, чехларның Казанга һөҗүмнәре башлану белән, семьясын җыеп, Казан артындагы Карауҗа авылына качты. Ләкин Г. Камалның ташкын йөрәге авылда качып ятырга чыдамады, ул Казанга әйләнеп кайтты.

Г. Камалның улы, яшь драматург Әнәс Камал, үзенең атасы турындагы истәлегендә бу чорны болай яза:

«Казанга чехлар керде.

Без Карауҗадагы туганнарыбыздан өйгә, Казанга, кайттык. Казан чын мәгънәсе белән ут эчендә. Көнтөн туп тавышлары гөрселди. Һавада туктаусыз шрапнель шартлый. Урамнарда ыгы-зыгы килеп йөргән офицерлар, погонлы солдатлардан башкаларны сирәк очратып була. Егетләрне, ирләрне солдатка алалар. Безнең ишек алдында гармончы Садыйк исемле картның үсеп җиткән улы Гатият абый бар. Картның улын солдатка җибәрәсе килми, әти белән киңәш итешә. Әти дә өйдән бер кая чыкмыйча ята. Без дә югары өйдә торырга куркабыз. Ул туп тавышларына дерелдәп кенә тора. Шуңа күрә түбән өйдә — карт өендә торабыз. Таш өй дерелдәми дә, тынычрак та шикелле тоела.

Семьяда ашау-эчү начар. Ара-тирә дәү әтиебез Галиәкбәр култык астына кыстырып кына азык китергәли. Ул кибетләрдә ашамлык нәрсәләренең күп булуы турында сөйли. Ләкин безнең әти бер җирдә дә эшләми. Шуңа күрә ашарга да ала алмыйбыз. Әтинең эш эзләргә уйлаганы да юк, өйдә утырырга да ярамаганлыгын белә. Шуңа күрә ул Гатият абыйга париклар киертеп, сакал-мыек ябыштырып гримлый. Ул чын карт кеше кыяфәтенә керә. Икесе дә өсләренә начар киенеп, кулларына корзиннәр тотып, ике бистә арасына шампиньон гөмбәләре җыярга чыгып китәләр. (Ул гөмбә бәрәңге белән кушып пешергәч, яхшы ук тәмле азык булып китә..

Бер көнне безгә әти өйдә юк вакытта ниндидер бер кеше килеп, әтине сорый, һәй ниндидер язу калдырып китә.

Кайткач, әтигә язуны бирәбез. Ул аны укып чыга да. шунда ук ачу белән ерткалап ташлый.

Ул борчыла һәм мыскыл катнаш көлү белән:

— Мине эшкә чакыралар. Баттал «Корылтай» газетасын чыгармакчы булган, имеш... Сезгә эшли торган Галиәсгарнең туасы бар әле, әфәнделәр!.. — диде-

Бу сүзләрне ул шундый көч белән әйтте. Мин бу кечкенә гәүдәле атамның шундый олы, шундый горур кеше икәнлеген беренче мәртәбә аңладым.

Аның шул вакыттагы горурлы позасы әле дә күз алдымда тора.

Шул көннән соң ул өйдә сирәк була башлады.

Гөмбәгә йөрү гадәтен ешайтты.

Бик соң кайта һәм иртә үк чыгып китә торган булды.

Теге кеше тагын берничә мәртәбә килде. Озын язулар язып калдырды. Без, әти авылга кайтып китте, дип әйтергә мәҗбүр булдык.

Бер көнне әти гадәттән тыш борчылган кыяфәт белән өйгә кайтып керде дә, өстәл янына килеп утырып, безгә күз йөртеп чыкканнан соң, үксеп-үксеп еларга тотынды. Без гаҗәпләндек. Аның янына җыелып, нәрсә булганлыгы турында сораша башладык. Ул күз яшьләренә йотлыгып:

— Хурлыгымнан елыйм, балалар, — диде.

Үзен-үзе кулга алганның соңында йөзенә җирәнүле төс чыгарып:

— Урамда Баттал очрады. Мине күрүе белән «Әле син исәнмени, сине ничек атып үтермәделәр соң әле?» дип китте, — диде.

Шул сүздән соң аяк-үрә басты:

— Булмас, атсагыз, атарсыз, сезгә хезмәт итмәм! — диде.

Аннан соң без аны өйдә очратмый башладык. 5л качып йөргән. Өйгә кайткалап киткән булса да, без аны күрә алмадык.

Көннәр күңелсез үтте.

Каты янгырлар китте. Тынгысыз шау-шулы көннәрне яуган янгырларның салмаклыгы бераз баскан шикелле булды.

Бер төнне янгыр гадәттәгедән катырак коя башлады.

Без азрән йокыга киткәнбез. Рәхәтләнеп тәмле төшләр күрен яткан да гына:

— Торыгыз, ничек итеп йоклап ята аласыз,— дип әти безне уятып йөри иде. Күзне ачуга искиткеч яктылык күзгә бәрелде. Яктырып таң аткан, кояш чыгарга якынаеп килә. Шундый тын, шылт иткән тавыш та юк.

Әтинең йөзе шатлык билгеләренә чумган, күзләре искиткеч яктылыкта чем-кара булып күренә. Күпереп торган саргылт мыеклары пөхтәләп шомарткан шикелле ялтырап торалар. Ул баскан урынында тора алмый, әле беребез, әле икенчебез янына килеп киендерешә.

— Тизрәк булыгыз, киенегез, үзебезнекеләр, кызыллар керде, — дип ашыктыра.

Тагы тормыш башланды.

Ул, гаскәриләр өчен чыгарыла торган «Эш» газетасында эшли башлады. Шигырьләр язды, спектакльләргә катнашты, барысына да өлгерде. Мин шуны гына хәтерлим: ул иртә үк редакциягә эшкә китә, аннан көндез дүрттә-биштә кайтып ашый да, репитициягә китә. Аннан кайта алса кайта, булмаса спектакльләрдә катнаша, төнлә инде шигырьләр, әсәрләр язу өстендә утыра.

Мондый өзлексез эш өстендәге тәүлекләр бик еш була. Ләкин ул аңар гадәттәге бер эш итеп кенә карый.

Сугышлар нәтиҗәсендә ватылып, җимерелеп беткән илне хуҗалык ягыннан торгызу кирәк, продуктлар җитешми, транспорт көчсез, утын, керосин шикелле нәрсәләр дә җитми.

Әтинең эш темпын туктатырга болар гына сәбәп була алмый. Өйнең салкын булуына, яндырырга лампа юклыкка да карамастан ул, аягына олы ката кия, иңбашына пальтосын сала да, үзе ясаган шәм яктысында төннәр буе яза. (Ул шәм, эче казылган чи бәрәңгегә туңмай салып, башына мамык урап кадап куйган шырпыдан тора.) Ул шундый шартларда эшләде.

Ул соңгы көненә кадәр үзенең көчен халык эшенә багышлады».

Кызыл Армия Казанны чехлардан тазарткач, 1918 нче елда беренче совет татар театры дөньяга килде. Бу — социалистлар комитеты инициативасы буенча, шушы юлларны язучы артист Г. Камал II тарафыннан оештырылып эшкә башлады. Совет татар театры үзенең эшен атнага бер тапкыр зур театрда, бер мәртәбә эшчеләр районында, бер мәртәбә артиллерия казармасында, кызыл гаскәрләр арасында алып бара башлады. Шул уңай белән театрга яңа репертуар булдыру аеруча әһәмиятле эш иде. Бу эшкә Галиәсгар Камал дәрт белән кереште һәм аның иҗаты яңадан киң рәвештә җәелеп китте.

1919 нче елның ахырларында Казанда Татар запасный батальоны каршында гаскариләр өчен татар труппасы төзелеп, эшкә керešте. Бер көнне Г. Камалның «Уйнаш» исемле драмасына читка бара иде. Залга акрын, салмак адымлы, җидди карашлы, аз сүзле Галиәсгар Камал килеп керде. Аның килүенә артистлар гаҗәпләнделәр. — «Уйнаш» уйналачагын Галиәсгар абзый кайдан ишетте икән, бүген әле яңа сайладык бит, әллә уйнарга рөхсәт бирмәс өчен килдеме? — диделәр. Г. Камал артистлар белән исәнләште дә, нәрсә куелачагын сорашты. «Уйнаш», диделәр артистлар.

— Бик яхшы, — диде Г. Камал. — Әгәр дә арагызга алсагыз, минем дә труппага керергә исәп бар,

«Уйнаш»та мулланы уйнап бирермен, ни әйтәсез? — диде.

Артистлар кул чабып каршы алдылар.

Фәкать яшьләрдән генә төзелгән труппа, Г. Камал шикелле, бер зур драматургның үзләре арасына эшләргә килүенә бик шатланды.

Г. Камал шунда ук батальонның штабына политкомиссар белән сөйләшергә барды һәм батальонга кызыл армеец итеп беркетелде.

Икенче көнне репитиция башлар алдыннан, өстенә соры шинель, башына папаха кигән, аягына обмотка ураган, сакал-мыегын кырган бер карт кызыл армеец залга килеп керде. Ул — Г. Камал иде.

Аның сакал-мыеклары кырып ташланганын күреп, кызыксынып калган артистлар: — Галиәсгар абзый, нигә сакалыңны кырдың, мулла ролен сакал белән уйнарга кирәк бит, — диделәр.

Г. Камал:

— Үз сакалым белән уйнагач ул натурализм була, без натурализм буенча спектакль куймыйбыз, реализм буенча куябыз. Вообще, артист булган кешегә сакал йөртү ярамый. Артист булгач, чын артист булырга кирәк, — диде.

Г. Камал бу труппада хезмәте белән, труппаның үсүенә, аның куйган спектакльләренең художество ягыннан эшләнешенә, тулылыгына зур ярдәм итте. Өендә булган барлык киемнәрен, бутафория нәрсәләрен ташыды, артистларга грим ясауда булышты. Матур, җылы йөрәкле, һәр яктан уйлап, тырышып Эшләнелгән образлар бирде.

Маршовый роталар чыгарганда уздырылган концертларда көлке куплетлар сөйләде. Батальонның китапханәсен аякка бастырды. Батальондагы бөтен кызыл армеецлар, командирлар, политруклар тарафыннан ихтирам ителә торган сөекле бер карт булып китте. Ул һәрбер җыелышта, һәрбер беседада, көлке сүзләр, тапкыр әйтемнәр белән кызыл армеецларның күңелен күтәрде.

Концерт белән аралаштырып куяр өчен, җиңелчә «Чиратлы чалбар», «Итекләр качты» исемле әсәрләр тәрҗемә кылды.

Автономияле Татарстан Социалистик Советлар Республикасы игълан ителгән көнне ул да урамнарда, мәйданнарда бирелгән концертларда актив катнашты. Татар Дәүләт Драма Театры төзелү белән профессиональ артист булып кереп, ныклап эшкә кереште. Шушы дәвердә «Имам Хәмзә», «Надежданың һәлакәте», Иблис», «Скапен хәйләләре» исемле әсәрләрне тәрҗемә итте. Татарда беренче мәртәбә, фольклордан файдаланып, «Корсын балам бу кала» операсын язды.

Г. Камал классик образлар тудыруда бик нык эшләде. Ул, Шиллерның «Юлбасарлар» трагедиясендә Патер, «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендә музыкант Миллер образларын, Максим Горькийның «На дне» драмасында актер образын тиңдәшсез рәвештә башкара иде.

Бу бөек драматургларның образларын сәхнә аша гәүдәләндерү өчен, Г. Камал драматургларның бөтен әсәрләрен укып чыга. Трагедия, драмаларның постановкалары турында чыккан тәнкыйтьләрне эзләп таба, аларны җентекләп тикшерә. Төрле театр постановкаларында булган кимчелекләрне булдырмау өчен бөтен көчен куеп тырыша. Образ өчен кирәк булган вак бутафория нәрсәләрен, вак детальләрне өендә үзе хәзерләп алып килә иде.

Алынган эшенә салкын карау, өстән генә уйлау. Г. Камал табигатенә ят нәрсәләр иде.

Г. Камал, уйнаячак рольләренең, язачак әсәрләренең һәрбер вак детальләренә кадәр уйлый, планын хәзерли, соңыннан гына эшкә керешә. Шуның нәтиҗәсе буларак, Г. Камалның һәрбер әсәре ремарка белән тулы.

Кайда да булса, нинди дә булса бер драма түгәрәге, Г. Камал әсәрен куярга хәзерләнеп, авторның үзен ярдәмгә чакырса, Г. Камал анда шатланып бара, түгәрәкнең эш процессларында һәр көн катнаша, режиссерлык итә, грим ясый, ярамаган җирләрен төзәтә, түгәрәк членнарының иҗат көчләрен күтәрүгә төрлечә ярдәм итә иде. Шуның өчен һәрбер завод, фабрика, артель, мәктәп Г. Камал характерындагы шундый күркәм якларны беләләр, аны һәр урында сөйлиләр, сагыналар.

Октябрь революциясеннән соң Г. Камал иҗатының күрелмәгән төстә чәчәк атуын әйткән идек инде. Чыннан да, Г. Камал Октябрьдан соң бик күп иҗат итте. «Көндәш», «Әйләнәм, ник өйләндем», «Хафизалам иркәм», «Җантаһир белән Җанзөһрә», «Өч тормыш» кебек драма, комедияләр язды. Клуб сәхнәләре өчен дистәләрчә инсцениpовкалар тудырды, бик күп әсәрләрне тәрҗемә итте. Гомумән Г. Камал йөздән артык оригиналь һәм тәрҗемә драма, комедияләр калдырды. Шуның өстенә ул, революциядән соң декламацияләр өлкәсендә аеруча эшчәнлек күрсәтте. Революция елларында ул декламацияләр, шигырьләр, ораторияләр, концертларда җырлау өчен куплетлар язды. Төрле постановкаларда Г. Камал ул декламацияләрне үзе дә сөйләп йөри иде.

Октябрьның бер еллыгы бәйрәменә карата Г. Камал «Нәсер» исемле оратория язды. Шул вакытта татар театры бәйрәм постановкасы әзерләде. Театр бер көндә дүрт җирдә спектакль, бер җирдә концерт бирде. Г. Камал боларның барында да катнашты һәм «Нәсер» белән чыгыш ясады.

Гомумән, бу чорда Г. Камал күрелмәгән дәрәҗәдә эшчәнлек һәм дәртлелек күрсәтә иде. Ул арыганны сизмәде, ял итү турында уйламады, әле яңа гына оешып, үсеп килә торган Советлар иленең культура үсеше өчен көн-төн хезмәт итте. Көндез ул газеталарда эшли, редакциядән үк репетициягә килә, спектакльдә катнаша, өйгә кайткач та төннәр буе утырып яза иде.

Мин сөям» исемле шигырендә ул болай дип язды:

«Мин сөямен халыкны, халыкны,
Хезмәт итәмен ялыкмый, ялыкмый,
Мин сөямен ирекне, ирекне,
Хезмәт итәм ирекми, ирекми.
Иптәш кызыкма данга һәм малга
Атла аякны алга да алга.
Мин сөямен ярлыны, ярлыны,
Ярлыларның барыны, барыны,
Мин сөямен эшчене, эшчене
Эш тормышның иң чыны, иң чыны».

Бу шигырьне Г. Камал бер язучы булу сыйфатында гына язмый. Ул — аның йөрәгеннән чыккан тойгылары, анда эш сөючәнлек, эшчеләр һәм ярлы крестьян массасын сөюлек, эш белән яну ачык күренә. Г. Камал һәрвакытта да үзенең үткен каләме, туры сүзе, уены һәм барлык эше белән хезмәт ияләре өчен тырышты. Шуның өчен дә Татарстан хезмәт ияләре 1929 нчы елда аның 30 еллык әдәби хезмәт бәйрәмен үткәрделәр. Татарстан хөкүмәте драматургка «Хезмәт батыры» исемен бирде.

Г. Камал соңгы елларына чаклы сәхнәдән аерылмый. Ул Наркомсобес клубына йөреп, клубның көндәлек эшенә актив катнаша, сукырлардан драмтүгәрәк оештыра. Сукырлар өчен «Күзсез мастерлар» исемле әсәр язып, үз режиссерлыгы астында аны сәхнәгә куя.

Г. Камал, иң соңгы оригиналь әсәре — «Өч тормыш драмасында революциягә хәтле эшчеләрнең һәм чыдамаслык авыр шартларда яшәүләрен, шул тормыштан котылып чыгу өчен, байлар, эксплуататорлар белән сыйнфый көрәш алып баруларын, хезмәт ияләренең бары Совет илендә генә бәхетле яшәүләрен күрсәтте.

Соңгы елларда Г. Камалның сәламәтлеге бик нык какшаган иде. Ул төрле вак авырулар белән авырды, ахырда эчәкләренә бизләр чыкты. Докторлар аңа операция ясап, бу бизләрне кистерергә киңәш иттеләр.

Г. Камал операция ясатырга риза булды.

Ләкин табигатьне гаҗәеп дәрәҗәдә ярата торган, урман, кырлар, суларны карап йөреп җанына азык җыярга гадәтләнгән Г. Камал, матур җәй көнендә больницага кереп ятасы килмәде. Көз җитү белән операция ясатырга уйлап, Татарстан Совет Язучылары Союзы тарафыннан бирелгән дачасына, Түбән Услон авылына күчеп китте.

Ул Казанга сирәк кайта иде. Соңгы мәртәбә кайтуы, Казанда туберкулез белән авырып ятучы энесе Габдулла Камал I хәлен белер өчен булды. Бу кайтуында ул анасы Мәүгыйзә белән сөйләшә һәм үзенең хәле зарарсыз гына булуын, һәрвакыт боржом суы эчүен, суның үзенә ярдәм итүен сөйләп утыра. Анасына да шул суны эчәргә киңәш бирә. Билгеле, ул үзенең берничә сәгать кенә гомере калуын белми.

Анасы белән сөйләшеп утырганнан соң ул Түбән Услонга кайтырга дип пристаньга төшеп китә. Ләкин аз гына сонга кала, ул килеп житкәндә су трамвае кузгалып китә.

Иренми торган табигатьле Г. Камал, берничә сәгать буе икенче трамвайны көтәргә теләми һәм Югары Услон перевозы белән Иделнең аръягына чыгып, җәяүләп Түбән Услонга юл тота.

Югары Услоннан 2 километр жир киткәч, юлда, Г. Камалның эчәкләренә чыккан бизләре аерым каты авырту белән авырта башлыйлар. Приступ башлана һәм аны якты дөньядан алып та китә. Бу — 1933 нче елның 16 нчы июне иде.

18 нче июньдә Казан хезмәт ияләре, үзләренең сөекле драматурглары, татар театрының атасы, классик язучы Галиәсгар Камал белән соңгы мәртәбә саубуллаштылар.

Галиәсгар Камал Казанда, Максим Горький исемендәге культура паркы эченә, туганнар каберлегенә күмелде.

Татарстан хезмәт ияләре Галиәсгар Камалның тууына 60 ел тулу көнен 1939 нчы елның гыйнварендә киң күләмдә билгеләп уздылар. Казанның бер урамына аның исеме бирелде. Шулай ук Татар Дәүләт Академия театрына да «Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры» дип исем бирелде, Г. Камалның туган йортына мемориаль такта куелды.

Г.Камал II.



Г. КАМАЛ ТУГАН ЙОРТ

(Элекке Суворов Хәйрулла йорты. Казан Г. Камал урамы, йорт № 29)

«Мин Галиәсгар Галиәкбәр улы Камал 1878 нче ел, искечә 25 нче декабрь, дүшәмбе көн, таң вакытында, Казанда элекке аркылы Тихвинский, хәзерге Фуксовский урамда, Суворов (хәзерге Хәйрулла Хәйруллин, Сувор Хәйрулла дип йөриләр) йортында дөньяга килгән».

Г. Камал.

Суворов Хәйрулла йорты Казанның Булак арты ягында хәзерге Г. Камал урамында урнашкан. Моннан 60 еллар элек бу тирәдә 10 —15 квартиралы йортлар булып, аның һәрбер квартирасында түбән сыйныф халык, кустарьлар, ямщиклар, көнлекчеләр урнашкан булган, шуның өчен бу район вак халык районы дип йөртелгән. Йортларның Ташаяк Исмәгыйль, мичче Гатаулла, Сая Ибрай дворы, Шакир солдат пулаты дип исем алулары — бу районда зур байларның булмавын ачык күрсәтәләр. Менә шул халык арасында, кустарь семьясында татарның атаклы драматургы Г. Камал дөньяга килгән.

Г. КАМАЛНЫҢ АТАСЫ ГАЛИӘКБӘР КАМАЛЕТДИНОВ

Габдрахман Камал II истәлекләре буенча ясалган

(худож. Б. Альменов рәсеме)

Галиәкбәр Камалетдинов тәбәнәгрәк буйлы, ачык сары сакаллы, кашлары күзе өстенә таба салынып төшкән ачулы кыяфәтле бер кеше була. Аның уен-көлкеле сөйләвен семьяда бик сирәк ишетәләр. Ул сүзгә бик саран, ләкин бик туры сүзле, үз фикерендә нык торучан бер кеше була. Үләр елларына кадәр балаларының алган профессияләреннән риза булмый, үзе белгәнчә балаларына «тәүфыйк» сорап теләк тели, тик соңгы елларында, Советлар хөкүмәтендә генә сәнгать эше гражданлык алганны күргәч, күңеле канәгать таба.

Галиәкбәр әвәлдә Мамадыш өязе (хәзер Арча районы) Сикертән авылында туып, 12 яшендә Казанга килеп байга кергән. 25 яшенә кадәр хезмәт итеп, кустарь-мехчы булып чыккан, үлгәнчегә кадәр шул эшендә дәвам итеп килде. (6, 7 битләрне кара.)

Г. Камал II

Г. КАМАЛНЫҢ АНАСЫ МӘҮГЫЙЗӘ КАМАЛЕТДИНОВА

Мәүгыйзә Камалетдинова йомшак табигатьле, кешегә мәрхәмәтле, үз балаларына сөйкемле, йомшак сүзле. Уен-көлкене бик яратучан бер хатын. Үз балаларының сәнгать кешеләре булуга ул ачуланмый, кайда да булса мәҗлесләрдә дин исеменнән сөйли торган абыстайлар Камалларның «гөнаһлары» хакында сөйли башласалар, ул: Минем балаларым безгә караганда бик күп артык гыйлемнәр, үз эшләрен үзләре белә торганнардыр, дип җавап бирә, һәм ире өйдә юк вакытларда, качып-посып театрга барып үз балаларының уеннарын караган.

Мәүгыйзә Камалетдинова, Арча районы иске Масра авылында яхшы тормышлы крестьян семьясында туган. (7 биткә кара.)

Г. Камал II

Г. КАМ АЛ УКЫГАН «ГОСМАНИЯ» МӘДРӘСӘСЕ

(Хәзер Тукай урамы, йорт №3). 1886 нчы елларда, Г. Камал Масра авылында укып кайтканнан соң, «Госманиягә» кереп укый башлаган.



«МӨХӘММӘДИЯ,, МӘДРӘСӘСЕ

(Тукай урамы ягыннан күренеше)

1895—96 нчы елларда Г. Камал «Мөхәммәдия» дә укый һәм шул вакытта демократик фикерле шәкертләр белән аралаша. Шиһап Мәрҗани, Каюм Насыйриларның әсәрләрен укый.

«Шул вакыт ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе тирәсендә ачылган өч класслы шәһәр башлангыч мәктәбендә Миргаяз Иманаев дигән учительдән русча да укырга керешә. «Адрес язарлык өйрәнсә өйрәнсен инде» дип аның бу эшенә Галиәкбәр агай да каршы тормый».

М. Гали.

ТУКАЙ УРАМЫ ЙОРТ № 5

(Элекке «Маҗар Фазлый» йорты)



«МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ

(Ишек алды як күренеше, ачык тәрәзә Г. Камал торган бүлмә)

Г. КАМАЛ
1893 — 1894 нче елларда

«Мин яшь, үз-үземне белмәгән бала вакытымда, әти һичбер вакытта үз-үзенә карар таба алмыйча бер квартирдан икенчесенә күчеп йөргәнлектән, ул заманның асламчы хатыннарыннан «Мәгъри астай» дип йөртелә торган бер хатын, минем әти белән, Кариев заманында артист булып озак вакытлар уйнап йөргән кешеләрдән «Ишми» дигән артистның атасы «Кара савыт Шаһи» дигән кеше хакында; «Кара савыт Шаһига хатын ярамый, камчатчы Галиәкбәргә фатир ярамый» дип шаяртып сөйли торган булган. Шулай итеп без бер фатирдан икенчесенә күчеп, бик күп йөри торгач, элекке Тихвинский урам хәзерге Тукай урамында Госманов мәдрәсәсе күршесендә «Мажар Фазлый» дигән кешенең йортына «фатир» күчкәнбез.

Минем үз-үземне белә башлавым әнә шуннан башлана. Бу квартирга без күчеп килгәндә әле без күчәчәк квартирның таш йорты эшләнеп бетмәгән иде, шул сәбәптән безне вакытлыга гына, капканың икенче ягындагы пулатның астындагы двор өенең бер почмагындагы, бер бүлмәгә урнаштырып торганнар. Шунда торганда, мин мич алдында уйнап утырганда, ут кабынып китеп күлмәгемнең алды ягы гөрләп яна башлаган, шунда хезмәт итүче Фазыл исемле дворник мәллә чикмәне белән каплап алып, утны сүндергән, мин дә корсакларым бераз пешү белән, янып үлүдән котылып калган идем. Әнә шул вакыйга беренче һәм һич онытылмый торган бер вакыйга булып исемдә калган».

Г. Камал
«Минем персональный пенсионер булуымнын тарихы»

Казан. Хәзерге Татарстан урамы, 21, 23, 25 нче номерлы йортлар. Бу йортларның һәркайсында Г. Камал торган һәм балалык вакытын уздырган.

«НАЧАЛЬНАЯ ШКОЛА». Г. КАМАЛНЫҢ РУСЧА УКЫГАН МӘКТӘБЕ
(Тукай урамы, йорт № 26)



«МӘГАРИФ». КИТАБХАНӘСЕ
(хәзерге Париж Коммунасы урамы)

Казанның гайбәт оясы, көфер почмагы булган Печән базарына нәкъ 1901 нче елның 1 нче маенда Галиәсгар абзый Камал, татар халкының башын әйләндергән, миен череткән «Бәдәвам», «Кисекбаш», «Бакырган» һәм башкалар шикелле чүп-чарлар бастырып таратып ятучы иске китапчылар, иске дөньяның үзәгенә кереп кечкенә бер кибет ача.

Шул чорларда үзләренең актык тиеннәренә үзләре язган китапларын бастырып, ничек халыкка җиткерергә, халык арасына таратырга белми гаҗиз булып йөргән Каюм абзый Насыйри, Гафур Коләхметов, Хөсәен Ямашев, Әбүзәревләр һәм башкаларның бастырган китапларын һәм алар язган әсәрләрне үзе бастырып халык арасына таратырга керешә.

Бик тиз арада бу кибет «Мәдрәсә Мөхәммәдия», «Касимия», учительская школа укытучылары, укучылары өчен оешкан бер почмак, аларның көрешү, фикер алышу, танышу урыны булып әверелә.

Халык арасына таратылган яңа тормышка өндәп, иске гореф-гадәтләргә, дингә каршы язылган яңа әдәбият та үз эшен эшли һәм Казан мәдрәсәләрен, учительская школаны бетереп төрле җирләргә таралган укытучы, укучылар аша таратылган яңа фикерләр, уйлар, өндәмәләр аркасында яңа фикерле, яңа Эзгә керүчеләр көннән көн арткан, үскәне күзгә бәрелеп тора иде инде.

1905 нче елгы революция чорларында аның «Мәгариф» китапханәсе исемендәге кибете чын бер революционный штаб булып әверелгән, анда яшерен матбага кисәкләреннән бастонка, хәрефләр, кәгазьләр саклана, басылган прокламацияләр, цензура тарафыннан тыелган газеталар, китаплар (яшерелеп калган кадәресе) шул кибет аша таратыла иде.

Бу елларда инде рус революционерлары белән дә нык бәйләнеш тоту, бергәләп эшләү күренә иде.

Полиция эзәрләүдән качып, төрле кыяфәткә кереп, я ламовой извозчик, яисә авыл мужигы булып киенгән «Алексей» кушаматлы рус революционеры, Хөсәен Ямашев, Коләхметов, Әбүзәревләр һәм башкалар килеп, кәгазь яисә башка басу кирәк-яраклары алып китәләр яисә бастырылган прокламацияләр китереп, таратырга калдырып китәләр иде.

Менә болар Галиәсгар абзый Камалның кечкенә генә, ярлы гына «Мәгариф» китапханәсе исемендәге кибет аша (дөрес әйткәндә, аңлылар арасында революционный штаб), халыкны караңгылыктан, коллыктан коткару юлында күрсәткән чиксез зур хезмәтләре.

1901 нче елдан 08 нче елга кадәр
«Мәгариф» китапханәсендә хезмәт итүчеләрдән
Габдулла Вәлиев.

Г. КАМАЛ
(Фото. 1900)

«Җитә 1900 нче ел. Мин инде «Мөхәммәдия» дә укып хәтме көтеп кылган бер егет. Ләкин бик тәүфыйксыз, азган, тузган бер егет: чөнки русча укырга да йөрим, театрга да барам. Җитмәсә тагы иптәшләр белән бергәләп юка кәгазь, копировка кәгазьләре куеп мәдрәсәдәге хәлфәләрнең җитешмәгән якларыннан көлеп, «Телескоп», «Мәнзарател галәм» дигән газеталар чыгарып, төнлә белән җәмәгать сәкеләренә ташлыйбыз...

Әтине димләп Казан байларының берсенең кызына өйләндереп, аннан иске зират өстенә мәчет салдырып, мине мулла итәргә телиләр. Мин өйләнергә риза булам, өйләнәм, ләкин... мулла булмыйм. Атам мехчы булганлыктан, мине мех сәүдәгәре ясамакчы булалар. Аңа да риза түгел. Аптырагач китапчы ясыйлар»

Г. Камал
«Яза башлавымның тарихы»

№ 2

آزاد خلق

(Свободный народъ).

АЗАТ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ

Г. Камал тарафыннан чыгарылган «Азат халык» газетасының 2 нче номеры

«1906 нчы елда Г. Камал «Азат халык» исеме белән газета чыгара башлый. «Азат халык» газетасы беренче номерыннан ук чын мәгънәсе белән сул фикерле газета булып чыга башлады. Ул газета «Йолдыз», «Вакыт» кебек буржуа газеталарына каршы көрәш ача.

Татар монархистлары, татар кадетлары тарафыннан оештырылган «Иттифакый мөслимин» җәмгыятенең, аның мәкәрҗә съездларының һәм думадагы татар депутатларының сыйнфи йөзләрен ачып бирергә тырыша.

Беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев һәм революционер язучы Гафур Колахметовлар ярдәме белән марксизмның нигезләре, социал-демократлар һәм аларның программалары турында, капитализм төзелешендәге каршылыклар турында озын-озын мәкаләләр баса».

М. Гали

«1905 нче ел революциясе иҗат көчләренең күзен ачты. Халык көрәш аркылы матбугат, әдәбият җилкәсендә берникадәр иркенлеккә ирешә. Г. Камалның да иҗат эшчәнлеге шушы чорда башланды. 1906 нчы елда «Азат халык» исеме белән демократик караштагы газета чыгарырга тотынды. Аның газетасы ирек сөюче халык карашында торды. Халык өчен, крестьяннар өчен, ирек, җир кирәклеге турында язды, татарның эре буржуа партиясе булган «Иттифакый мөслимин» партиясенең программасына каршы чыкты. Патша Россиясенең пычрак күренешләрен фаш итә торган фактларны халыкка белдерде. Шул рәвешчә ул халыкны демократик карашлар белән тәрбияләүдә булышты».

Г, Кашшаф, И. Вахитпов.

«АЗАТ ХАЛЫК» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ УРНАШКАН «САРАЙ» НОМЕРЛАРЫ



Пролетариатның бөек язучысы Алексей Максимович Горькийның татар әдәбиятына тәэсир идүе гаять көчле. Татар пролетариат әдәбиятының башлануы да М. Горький исеме белән бәйләнгән. Шул әдәбиятның татар телендә беренче үрнәкләрен биргән Гафур Коләхметов М. Горький иҗаты белән рухланып эш итте. Шәриф Камал кебек язучылар үз иҗатларын М. Горький йогынтысы белән үстереп җибәрделәр. Г. Камал М. Горькийның «На дне» (Тормыш төбендә), «Мещаннар» исемле драмаларын татар теленә тәрҗемә итеп, беренче башлап аларны татар сәхнәсенә мендерде.

Беренче татар большевигы
ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ

1905 нче ел революциясе чорында Г. Камал тарафыннан идарә ителә торган «Мәгариф» китабханәсенең роле бик киңәя.

Ул вакыттагы татар социал-демократлары һәм беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев татар халкы арасында социал-демократик прокламацияләр таратуда «Мәгариф» китапханәсеннән файдаланалар.

Г. КАМАЛ
(Фото, 1902)

ГАБДУЛЛА КАМАЛ

(Артист Камал I)

Г. КАМАЛ ҮЗЕНЕҢ ЮЛДАШЫ ГАЙШӘ ХАНЫМ БЕЛӘН
(Бу рәсем 1908 нче елда Мәкәрҗә ярминкәсендә алынган. Рәсем өч бармак кадәр калай пластинкага эшләнгән)



Халык шагыйре
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ



КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ УЙНАЛГАН СПЕКТАКЛЬ АФИШАСЫ

«Татар telendә куелган беренче спектакльнең афишасын да Г. Камал үз кулы белән язды. Ул спектакль 1906 нчы елның 22 нче декабрендә (иске стиль белән) булды һәм фәкыйр студентларга ярдәм итү теләге белән куелды».

Г. Кашшаф, И. Вахитов.

ТЕАТР

Халыкка дәрес гыйбрәтдер театр
Күнелдә йоклаган дәртне уятыр.

Театр — яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, унга илтә,

Театр — көлдерәдер, уйнатадыр
Тагы, үткән гомерне уйлатадыр.

Күрерсең анда үз хәлең: көләрсең,
Көлерлек булса; булмаса, жыларсың.

Күрерсең: тормышың нинди, җитешме?
Җитеш булмаса кай җире җитешми.

Төзәтерсең шуны, тәкмил итәрсең,
Шулай шактый белем тәхсил итәрсең.

Г. Тукай.



ГАФУР КОЛАХМЕТОВ



Г. КАМАЛНЫҢ КУЛЪЯЗМАСЫ

(«Беренче театр» комедиясеннән бер бит)

«Беренче театр» Г. Камалның иң беренче һәм иң уңышлы язылган комедияләреннән берсе булып тора.

Г. Камал ул татар театрын оештырып, аның өчен беренче репертуарларны язу белән генә канәгатьләнми. татар театрының башлану чорын, ул дәвердәге буржуазиянең культура дәрәҗәсен, театрга карашын һәм анар каршы булган көрәшне җанлы картиналар аша гәүдәләндереп, үзенең шушы классик комедиясен яза. Һәм шуның белән татар театрының башлану чорын тарихка кертеп мәңгеләштереп калдыра».

М. Гали.



Программа

ТАТАРСКАГО СПЕКТАКЛЯ, имѣющагося быть въ пользу недостаточныхъ учениковъ Казанской Татарской учительской школы.

22 Декабря 1906 года.

I.

„Кызганычъ Бала"

или

„НЕСЧАСТНЫЙ ЮНОША."

драма въ 5-ти дѣйствіяхъ.

Участвующія лица

Халилъ, купецъ	Субаевъ.
Тагира, его жена	Галеева.
Шафика, ихъ дочь	З. Тарханова.
Шарифа старушка	Г. Терканова.
Гата	Базарджануровъ.
Служанка	„
Докторъ	Бакировъ.

II.

„ГИШК БЯЛЯСИ"

или

„ИЗЪ-ЗА ЛЮБВИ"

комедія въ 4-хъ дѣйствіяхъ.

Участвующія лица:

Адибъ-Бекъ, сынокъ богатаго купца	М. Сями.
Загида, старуха	Шамсутдинова.
Шамсутдинъ, купецъ	Тинеевъ.
Джамила дочь купца	Муратова.
Камила жена купца	Хадяева.
Габдульсаматъ, законоучитель	Газизовъ.
Гусманъ, работникъ Адиб-Бека	Хайбушевъ.
Сагида, служанка	Г. Тарханова.
Лутфы, приказчикъ купца	Исмагиловъ.

ПОСЛѢ СПЕКТАКЛЯ ТАНЦЫ.

Начало ровно въ 8½ часовъ вечера.

پراغراما

قزانده تاتارچه تیاتر

I

قزغانچ بالا

II

عشق بلاسی

КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ КУЕЛГАН СПЕКТАКЛЬНЕҢ ТАТАРЧА-РУСЧА ПРОГРАММАСЫ

ТАССР ның атказанган артисткасы

С.-Ж. ГЫЙЗЗАТУЛЛИНА — ВОЛЖСКАЯ

«Кызганыч бала» драмасында Шафика ролендә.

«Бер заман «Шәрык клубы» ачыла. Мин клубта старшиналарның берсе. Клубны зурайтыр өчен башында Сәхибҗамал Гыйззатуллиналар торган «Сәйяр» труппасын яллыйбыз. Бер куйган пьесаны ике куйсаң халык килми. Халык яңадан-яңа пьесалар сорый. «Уйнаш» ны да язып карыйм. «Дәҗҗал» да языла, башкалар да. Труппа һаман да туймый».

Г. Камал.

«Яза башлавымның тарихы».

Г. Камал татар матбугат һәм әдәбиятында иң башлап дип әйтерлек тәрҗемәчелек эшенә керешеп, шул өлкәдә күп эшләгән язучы.

Ул тәрҗемәчелек эшенә оригиналь әсәрләр яза башлау белән бер үк вакытта керешә. Анын иң беренче әдәби тәрҗемәсе булып атаклы төрек язучысы Намыйк Камалның «Зәвалле чуҗык» дигән әсәре «Кызганыч бала» драмасы хисаплана.



«МӘГАРИФ» КИТАПХАНӘСЕ
(Казан. Париж Коммунасы урамы)

1906—1907 НЧЕ ЕЛЛАРДА Г. КАМАЛ ТОРГАН ЙОРТ
(Тукай урамы. Югарыда ялгыз тәрәзә аның квартирасы)

1910 нчы елда Казандагы «Шәрык клубы» яңа бинага күчкәннән соң Г. Камал һәм Гафур Колахметовларның инициативалары белән «Сәйяр» труппа артистлары айлык хезмәт хакы алып эшләргә керешәләр. Шул сезонда Г. Камал труппада режиссерлык итә. Ул үзенең туган энеләре Габдулла һәм Габдрахман Камалларны шул ук труппага артист итеп ала.

1910 НЧЫ ЕЛДА «ШӘРЫК КЛУБЫ» УРНАШКАН ЙОРТ
(Уңда өч катлы)

Г. КАМАЛ
(Фото. 1908)

Г. Камал иске шәрык феодализмына һәм татарның черек буржуа-мещан тормышына каршы сугыш ача. аның бөтен кабахәтлекләрен, түбәнлекләрен, ваклыкларын һәм ямьсезлекләрен ачып бирә. Иске «Бәдәвамчыларга» каршы «Безнең дә телебез бар» дип күтәрелеп чыга һәм шуның белән гасырлар буе татар халкын каплап килгән караңгылык пәрдәсен алып ташлауда зур хезмәт күрсәтте».

М. Гали

Городъ СИМБИРСКЪ.

Театръ Д. С. БУЛЫЧЕВОЙ

ПРОГРАММА.

Въ Пятницу, 21 Іюня 1913 года,

ПЕРВЫЙ

МУСУЛЬМАНСКІЙ СПЕКТАКЛЬ

любителей драматическаго искусства.

Первый разъ будетъ поставлено въ г. Симбирскѣ

ПОДЪ НАЗВАНІЕМЪ

УЙНАШЪ

(ИЛИ ИЗМѢНА СУПРУГА)

драма въ 3-хъ дѣйствіяхъ соч. Г. КАМАЛЪ.

Дѣйствующія лица:

Анверъ, богатый татаринъ, ... много ...	А. Кильдишевъ.
Ахмедзянъ, средній купецъ, ѣздитъ по ярмаркамъ	Бари Тарханскій.
Сарвеѣ Замалъ, жена Ахмедзяна	Гизульбанатъ Кильдишева.
Муглифа, хитрая сваха, любившая много обманывать	Туктарова Фатыма.
Фатрахманъ, хитрый маклеръ	К. Ишуковъ.
Антри, пьяница хулиганъ	Бари Тарханскій.
Мулла	Ф. Сайфутдиновъ.
Пріѣзжій ...	Волжскій.
Пьяница—татаринъ	Ишмухаметовъ К.
Свидѣтели, Ахмедъ и Сафа	Камскій. Арсланонъ.
Домохозяинъ	А. Саидовъ.

Послѣ спектакля

КОНЦЕРТЪ

на татарскомъ языкѣ.

Начало ровно въ $8^{1}/_{2}$ часовъ вечера.

Администраторъ А. Кильдишевъ.

Режиссеръ К. Ишуковъ.

Суфлеръ А. Габидъ.

Тип. ... Симбирскъ, 1913 г. ...



«УЙНАШ» ДРАМАСЫНЫҢ ПРОГРАММАСЫ

Артист Барый Тарханов тарафыннан Сембер (Ульяновск) шәһәрендә куелган спектакль программасы. Программы ефәккә басылган. (1913)


kitsm. (Ənvar bislek kəƣəz cƣarьp, Moƣlifənen qulьna qstьra. Moƣlifə aƣcanь qarap) Bu ni digən eşen bu? Monьŋ ocen ber atna bujь sөjrəlep jөrrgə, əllə mine divana dip beldeŋme? Az digəndə ber ille tөŋkə də bulmaƣac, min anьŋ artьnnan eş qaldьrьp jөrimme suŋ!

Sərvi çamal - (Yz aldьna) Ja rəbbi xoda-jьm, xəjrlegəgnə bula kyrsen. Tөrəkləren betnnəj sikerə. Mine aldamasalarьgna jarar ie. Əllə nindi jəşren syzlər sөjləşələr buƣaj.

Ənvar - Mə inde alajsa! (Ber ni qədər kəƣəz aqcalar cƣarьp, Moƣlifənen ucьna qstьra)

Moƣlifə - Tarbj igelegen kyr. Əjdə, ikegezne kyrştrim. (Sərviçamal janьna barьlar.) Əjdə ulьm, ojalma, ojalma, hi bəpkəm, psi balasь şikelle posop-gna, ojalьp-gna tora. Ɵzьm, sin də ojalma, kyreşegez, kyreş! (Jatxraxtan krep, ber aƣac artьna posьp, tьŋnap tora.

Ənvar - (Aƣrьnƣna) Tsənmesez? (Utьra)

Sərvicamal - (Qulьn birep, Ojalьp-gna)

«УЙНАШ» ДРАМАСЫНЫҢ КУЛЪЯЗМАСЫ

«Уйнаш» драмасы Петропавловск шәһәрендә «Миңа бар да бер» исеме белән уйнала.

Г. КАМАЛ
(Фото. 1910)

Драматург буларак Г. Камал татар әдәбият дөньясы өчен бик бай һәм кыйммәтле мирас калдырган язучы. Чын сәнгатьчә эшләнү ягыннан татар художество әдәбиятының драма һәм комедия өлешендә иң беренче карлыгачлар булып аның әсәрләре хисапланалар.

Г. КАМАЛ
(Фото. 1912)

1911 нче елда Балкан сугышы башлангач, Г. Камал «Йолдыз» газетасының даими хәбәрчесе булып Төркиягә китте. Ул елны Төркиядә каты суыклар булып, карлы-бозлы яңгырлар яуды. Г. Камал Төркиядән авырып, аягы-кулы хәрәкәтсез хәлдә кайтты. Рәсемдә аның авырган вакыты.

Г. КАМАЛ ЮЛДАШЫ ГАЙШӘ ХАНЫМ ҺӘМ УЛЫ ӘНӘС БЕЛӘН
(Фото. 1911)

Г. Камал ул татар әдәби телен үстерүдә иң зур практик эш күрсәткән язучы, Каюм Насыйрилар тарафыннан ташланган «татар телендә язу» логунгысын иң башлап тормышка ашырырга керешүче һәм шул юлда иң күп эшләүче язучы һич шиксез Г. Камал. Г. Камалны, бер яктан, татар театрының һәм татар сәхнәсенең атасы дип атасак, икенче яктан, аны татар әдәби проза теленең дә атасы дип атарга тиеш булабыз».

М. Гали.

«Г. Камал иҗаты һәм аның юлдашы булган татар театры белән, татар әдәбиятында сәнгатьчә формалашкан драма жанры мәйданга килде дип әйтә алабыз. Һәм бу драматургия аңа кадәрге татар әдәбиятына эчтәлеге белән дә, стиле белән дә ошамады, чөнки ул икенче социал - политик шартларга һәм сыйнфый карашларга җавап бирүче иде. Г. Камал драмаларының темасы татар әдәбиятында бөтенләй яңа объектны яңача гәүдәләндерүгә нигезләнгән иде».

Г. Халит.

Г. КАМАЛНЫҢ СЕҢЛЕСЕ МӘРЬЯМ

Г. КАМАЛНЫҢ ИПТӘШЕ ГАЙШӘ ХАНЫМ УЛЫ ӘНӘС ҺӘМ ТУГАННАРЫ БЕЛӘН

«Г. Камал үзе яшәгән чордагы барлык социал каршылыкларны ачучы һәм сәнгатьтә, театрда үткен итеп яктыртучы булып татар әдәбиятына чыкты. Бу — Г. Камал иҗатының бер оригиналь ягы һәм социаль-актуаль тавышы булды. Кече яшеннән үк татар мещаннарының караңгы әйләнә - тирәсе эчендә, һәр төрле «хикмәтләр» гә төренгән көнкүрешендә күпне күреп үскән Г. Камалның каләме башта ук үзе сынаган һәм нәфрәтләнгән чынбарлыкка кадалды»

Г. Халит



Г. КАМАЛ, М. ГАФУРИ, ҺАДИ ТАКТАШ

(1929)

Г. Камал татар буржуаз тормышының купшылыкка төренгән ак өйләренә һәм идеаллаштырылган гүзәл дип табылган вәкилләре янына да һәм кер кунмаган парадныйларыннан да килеп кермәде, арткы кара өйләренә, караңгы һәм лакланмаган парадныйларыннан килеп керде, нәфрәткә очрады, һәм ул нәфрәткә нәфрәт белән җавап кайтарды, көлү аша аны ләгънәтләде. Чөнки чын сәнгать алдындагы бурыч — буржуаз җәмгыятьнең идеаллаштырылган тормышы турындагы хыяллардан гыйбарәт түгел. Ул изү чыганагы булган шул җәмгыятьнең нигезен җимерергә хезмәт итә. Бөек интересларга һәм чын идеалларга хезмәт итүче художник өчен бердән-бер дөрес юл шул иде. Г. Камал бу дөреслекне тапты һәм шуның белән ныгып калды. Шуңар күрә мещан-буржуатормышына булган мөнәсәбәттә шул җәмгыятьнең йөзен ачы көлү аша ачып салуны да Г. Камал үз иҗатының дөрес объекты һәм коралы итеп бик уңышлы сайлый да алды. Чөнки Г. Камалның дөньяга карашы, демократик интереслары табигый һәм зарури рәвештә аны шул якка алып чыкты»,

Г. *Халит,*

Г. КАМАЛНЫҢ ХАЛЫК АРАСЫНДА ИҢ КҮП ТАРАЛГАН ПОПУЛЯР РӘСЕМЕ

«— Татар драматургиясенең ныклы фундаментын төзеп, аңа стена салуга керешүче Галиәсгар Камал.
— Татар әдәбиятында комедияне тудыручы һәм аны үстерүче Галиәсгар Камал.
— Татарда юмор һәм сатира әдәбияты тудырып, аны массалаштыручы Тукай белән Галиәсгар Камал».

М. Гали.

«ЙОЛДЫЗ» ГАЗЕТАСЫНЫҢ РЕДАКЦИЯСЕ УРНАШКАН ҺӘМ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ Г. ТУКАЙ ТОРГАН «БОЛГАР» НОМЕРЛАРЫ

1914 НЧЕ ЕЛДА УЙНАЛГАН «УЙНАШ» АФИШАСЫ



МУЛЛАНУР ВАХИТОВ ТАРАФЫННАН ОЕШТЫРЫЛГАН МӨСЕЛМАН СОЦИАЛИСТЛАР КОМИТЕТЫ УРНАШКАН ЙОРТ

(Тукай урамы № 1) Г. Камал М. Вахитов һәм аның «Кызыл байрак» газетасы белән якын бәйләнештә булды.

Г. КАМАЛ СОҢГЫ ЮЛДАШЫ АСМА ХАНЫМ БЕЛӘН
(Фото. 1918)

Г. *КАМАЛНЫҢ АНАСЫ МӘУГЫЙЗӘ АБЫСТАЙ КЫЗЫ ЗӘЙНӘП, СЕҢЛЕСЕ ГАЗИЗӘ БЕЛӘН*

Г. КАМАЛ
(Фото. 1927)

«Г. Камал буржуа-мещан вәкилләренең кабахәтлеген, вакчыллыкларын, аңгыра һәм тискәрелекләрен ачып салуда үзенең көлү осталыгын күрсәтте. Көлүнең дошман белән көрәшүдә зур көч икәнен аңлап эш итте».

Х Хәйр

«Татар театрын нигезләүгә, әсәр белән генә түгел, киемнәрем, уеннарым белән дә күп кенә ярдәм иткән идем. Татар буржуазиясе моның өчен мине кырый гына какты. Ул байгуралар театрны үстерүгә ярдәм итү түгел, бәлки һаман без башлаган эшләрне сүндерергә тырышалар иде».

(Г. *Камал.* «Яза башлавымның тарихы»)

Г. КАМАЛ
(Фото. 1927)

«1919 нчы елда запасный батальон каршында үзенең энесе артист Габдрахман Камал II тарафыннан төзелгән татар труппасында артист булып эшли. Аннан соң эшчеләрдән төзелгән труппага кушылып, хәзерге Вахитов заводы клубында уйный. 1920 нче елда хөкүмәт тарафыннан төзелгән Татар Дәүләт Театрында эшли».

Г. Кашшаф, И. Вахитов.

АРТИСТ ГАБДРАХМАН КАМАЛ II

Г. КАМАЛНЫҢ КЫЗЫ РӘФИКА

Г. КАМАЛНЫҢ УЛЫ АРТИСТ, ДРАМАТУРГ ӘНӘС КАМАЛ

(Фото. 1940)



«ХАФИЗАЛАМ ИРКӘМ» ПЬЕСАСЫНЫҢ КУЛЬЯЗМАСЫ

(1922)

«Бу («Хафизалам иркәм») әсәрдә ул авыл яшьләренең революция елларындагы тормышын гәүдәләндерә, ярлыларнын бердәмлекләрен күрсәтә, элеккечә хезмәт халкыннан көләргә, аларны мәсхәрәләргә йөргән кулак-куштаннарны жиңеп, хезмәт ияләре яшьләренең яңа тормыш коруларын, хорафәтләрдән, диннән азат булган туй ясауларын сурәтли».

Г. Кашшаф, И.Вахитов,

Г. КАМАЛ

(1929)

«Г. Камал — татарда комедия тудыручы. Ул бу өлкәдә классик үрнәкләр калдырды. Аның «Беренче театр», «Банкрот», «Бүләк өчен», «Безнең шәһәрнең серләре» кебек әсәрләре көчле сатира кулланылып язылдылар».

Г, Кашшаф, И. Вахитов.

ХУДОЖНИК Г. АРСЛАНОВ ТАРАФЫННАН ЯСАЛГАН ШАРЖ. (1929)

1929 нчы елда булган соңгы юбилее уңае белән аңар Советлар иленең төрле почмакларыннан йөзләрчә котлау хатлары һәм телеграммалары килә. Шул ук вакытта ак эмигрантлар да «котлау» телеграммасы җибәрәләр. Г. Камал телеграмманы тирән нәфрәт белән каршы ала. (46 битне кара.)

Г. КАМАЛНЫҢ АТА-АНАСЫ КҮП ЕЛЛАР ТОРГАН ЙОРТ

(Сафьян урамы, йорт №14)


№ 93 (2463)

ريداكسييهگه خات.

Г. КАМАЛНЫҢ «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНА ЯЗГАН АЧЫК ХАТЫ

Редактор иптәш!

Минем шушы хатыма газетада урын бирүегезне үтенәм.

Минем 30 еллык хезмәт бәйрәмем уңае белән, бәйрәмгә катнашкан, мине тәбрикләгән оешмаларга, аерым иптәшләр театр һәм концерт кичәләрендә катнашкан артист, артисткалар һәм ул театр, концертларны оештырган иптәшләрнең һәммәсенә бердән тәшәккеремне белдерәм.

Шуның белән бергә, Германиянең Берлин шәһәрендә ирекле Совет иленең дошманнары, контрреволюцияче. татар ак эмиграциясе тарафыннан чыгарыла торган «Милли Юл» журналы редакциясе тарафыннан жибәрелгән тәбрик телеграмманың үзем өчен тәбрик түгел, бәлки хурлык санаганымны әйтеп үтәргә тиеш табам. Бигрәк тә телеграмманың «Ирекле көннәр житкәнгә тикле» дигән урыннары, бу телеграмманын пычрак ният белән язылган икәнлеген күрсәтәләр. Минем 30 еллык хезмәтемнең 12 елы тулы ирекле, Совет дәүләтендә үтте. Бу 12 елның киң мөмкинлекләр бирү ягыннан башкаларга чагыштыра алмаслык аермалары бар. Шуңа күрә Гаяз әфәнделәр көткән «ирек»нең минем өчен һич кирәге булмаганын үземнен андый ирекләрнең чын дошманы булуымны белдерәм.

Галиәсгар Камал

Казан, 1929 нче ел, 24 нче апрель.



ГАЛИӘСГАР КАМАЛ
(Фото. 1930)

Орденлы язучы һәм драматург
ШӘРИФ КАМАЛ

РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе
орденлы драматург
ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ



Г. КАМАЛ
(1932)

Г. КАМАЛНЫҢ СЕҢЛЕСЕ — АРТИСТКА
ЗӘЙНӘП КАМ АЛОВА

Г. КАМАЛ ҮЗЕНЕҢ СЕМЬЯСЫ ҺӘМ КАРДӘШЛӘРЕ БЕЛӘН ЮДИНО РАЙОНЫ, КҮЗӘМӘТ АВЫЛЫНДА ДАЧАДА



Г. КАМАЛНЫҢ ҮЛӘРЕННӘН 12 КӨН ЭЛЕК ТӨШКӘН ИҢ СОҢГЫ РӘСЕМЕ

(1933)

Г. КАМАЛ ТАБУТТА

Г КАМАЛНЫҢ ГӘҮДӘСЕН КҮМӘРГӘ АЛЫП БАРУ



Г. КАМАЛНЫҢ МАСКАСЫ

Г. КАМАЛНЫҢ ИҢ СОҢ ТОРГАН ҮЗ ЙОРТЫ

Г. КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ КҮРЕНЕШЕ

Г. КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

«Г. Камал татар җәмгыятенә ничек яңа пафос алып чыккан булса, татарның беренче театры да шуның илһаме белән үзенең беренче пәрдәсен ачты... Татар театры демократик юнәлештә чыкты, чөнки аның сәхнәләрен һәм караучыларың илһамландыручы һәм башлап нигез ташы салучы вәкил — демократик язучы Г. Камал иде»

Г.Халит

Минемчә реализм, детальләрнең дөреслегеннән тыш, типик характерларны типик шартларда дөрес гәүдәләндерүне аңлата.

Ф. Энгельс.

Искусстволар тарихын өйрәнү, көлүнең сыйнфый көрәш коралы булу ягыннан һәрбер вакытта да үзенең тәэсирен югалтмаганлыгын күрсәтә...

Көлүче кеше, көлкегә алынган кешесеннән үзенең югары торганын аңлый. Ул дошманында булган йомшак якларын ачып салырга тырыша, ә йомшаклыкны ачып салу — социаль маневрлар ясауда зур эш ул...

Көлү үзенең тиешле тәэсирен ясасын өчен, барыннан да элек, көлүче кеше үзе дошманның түбәнлегенә ышанган булырга тиеш; икенчедән, көлке кемгә юнәлтелгән булса, шул кешенең үзендә үзенә карата бүтән бәя бирүне тудырырга тиеш, һәм өченчедән, көлү — шаһитлар каршында ышандырырлык булырга, аларда сатирикның үз дошманын җимерергә тырышуына теләктәшлек тойгысын тудырырга тиеш.

А. В. Луначарский.



یاش یکت هم قزلرغه نمونه (اورنک)

بختسز یکت

— درام —

آلطی پرده ایله تألیف ایدلمشدر .

باصمه‌سنه رخصت ویرلدی سانکت پیطربورغده ۱۸ نجی ایولده
۱۸۹۹ نجی یلده

КАЗАНЬ.
Типографія Торговаго Дома Братьевъ Каримовыхъ
1900 г.

«БӘХЕТСЕЗ ЕГЕТ» ДРАМАСЫНЫҢ (БЕРЕНЧЕ БАСМА) ТЫШЛЫГЫ
1900 нче ел Казанда Кәримевләр матбагасында басылган



«Ошбу сәнә (ел) 5 нче ноябрьда «Новый клуб» залында «Сәйяр» мөселман артистлары тарафыннан Галиәсгар әфәнденең 10 сәнәле әдәби вә милли каләм хезмәте шәрәфенә, аның «Бәхетсез егет» драмасы илә «Бүләк өчен» комедиясе куелды.

Бу юбилейны мәхәлли хөкүмәтнең әмере илә афиша вә летучкалар да игълан итмәк мөмкин булмаганга, спектакльгә килгән халык мөтәнаттин булуы матлуп, бу кичә өчен бик аз диярлек дәрәҗәдә генә иде.

Галиәсгар әфәнденең бу ике әсәре чын татар тормышыннан, бик белеп алынган тасвирлар булып, хосусән «Бүләк өчен» дәге улын өйләндерә торган татар хатынының халәте рухиясен белү, аның издиваҗ кеби олуг бер эшкә ничек бер уенчык кына итеп караганын күрсәтү вә шул хатын авызыннан, кыз атасы тарафыннан киләчәк бүләкләрне әлхам укыган кеби яңлыштырмый, гармоничный санату фәкать Галиәсгар әфәнденең нечкә хисенә вә тирән күрүенә генә хас бер эш булганга, аннан соң «Сәйяр» труппа артистларының сәхнәдә һәрвакыт, һәр жирдә, һәр шәһәрдә күрсәтәчәк мабиһелифтихарлары шушы Галиәсгар әфәнде әсәрләре булганга — шул сәбәпле алар күп уйналганга бу әсәрләрне уйный белүдә артистлар бөтенләй мөтәхассис булып киткәнгә, табигый уен яхшы чыкты.

«Бүләк өчен» уйналып пәрдә төшкәч, бөтен халык күңелендә бу уеннан калган гүзәл бер хис, аларны үз үзләрен бөтенләй оныттырганга, бөтен залга тәбрик һәм кул чабу тавышлары яңгырады!..

Минем күңелемдә Галпәсгар әфәнде әсәрләренә моннан әллә ничә еллар элек, ярты сабый вакытымда ук мәхәббәт орлыклары чәчелгән иде. Аның әсәрләрен бу елларда сәхнәдә күрә, күрә вә муәффәкыятенә тәгаҗҗеп итә-итә шул мәхәббәт һаман үсә бара, тамыр җәя барадыр.

Мин бу юбилей кичәсендә Галтәсгар әфәндене алгы сафтан торып тамагым карылганчы кычкырып тәбрик иткәнем кеби, хәзер дә тәбрик итәм:

«Син мөхтәрәмсең, синең эшең халык файдасына булды. Синең язганнарың мәңге безнең күңелемездә калачак!» дип игълан ителгән мөкаддәс бер чакта мәгъһуд Камал үз рухының матур ягып вә идеалының изге икәнен халык көзгесеннән үз күзенә күрсәткән чакта күңеле тулмаган кеше таш йөрәкле булырга тиештер.

«Мөбарәк булсын сезнең ун еллык хезмәтегез!»

Һәм дә татар тормышының, Казан мещаннарының иң безгә мәчһул почмакларын сәхнәдә якты кояш кеби күрсәтүгә каләменең көченнән килгәненә хайрәт итәрәк аны — Галиәсгар әфәндене «татар Островские» бинам мөкәррәм вә мөстәхикы белән тәгъзим итеп сүземне бетерәм».

Г. Тукаев.

17 нче ноябрь, 1910 нчы ел.

«Мөхтәрәм әдибемез Галиәсгар әфәнде!

Без, берничә кешедән гыйбарәт труппа театр хезмәтен әда кылу өчен дөньяга чыктык. Безнең дөньяга чыгуымызга Сез Галиәсгар әфәнде сәбәп булдыгыз. Сезнең язган әсәрләрегездән «Бәхетсез егет» бүген утыз җиденче мәртәбә сәхнәгә куеладыр. Шул мөддәт эчендә бөтен җан вә тәнемез илә Кырым, Кавказ һәм Россиянең башка шәһәрләрендә Сезнең әсәрләрегезне, без «Сәйяр» труппа артистлары бөтен гали хисләремез илә вежүдкә чыгару өчен иҗтиһад иттек. Без «Сәйяр» труппа артист вә артисткалары Сезнен ошбу гали хезмәтләрегезне тәкъдир итәмез- Яшә Галиәсгар әфәнде!

Яшәсен Сезнең кувәи тәхририягез!

С-Ж. *Гыйззатуллина, Ф. Сәмитова, Ф. Әхмедова, Ә. Мостафина, Г. Кариенв Г. Лашушев, д. Кулалаев, Г. Болгарская, К. Шамиль* ».



Кәрим бай — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисты — орденлы

З. СОЛТАНОВ

Җәмилә. Мин балдан бирле үземнең кайда утырганымны да белмәдем. *(Самовар янынарак урындык алып утыра.)* Уйлый-уйлый әллә нинди уйларга төштем; бераз елап та алдым. Бала булгач, начар булса да кызганыла икән. Ахыры ни булып калыр инде. *(Елый башлый.)* Мондый эшләр аслан... нәселебездә... булганы юк иде... аллаһе тәгалә үзе... инсаф бирмәсә... кешенең үгетләве белән генә... булмый икән! *(Елый, яулыгы белән күзен сөртә.)*

Кәрим. Юкка кайгырырга ярамый. Аның өчен кайгырып һич файда чыкмый. Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс; аңа биргән үгетне бер эткә бирсәң, ул да бераз әдәпләнер иде. Үзенә калса, шулай булып йөрүе бик килешә дип белә торгандыр. Андый эшкә керешкән кеше, һичбер вакытта да кеше була алмый инде ул. Андый эш белән эштән чыгып, бар малыннан аерылып, ахырында адәм мәсхәрәсе булып садакага йөреп үлгән кешенең очы-кырые юк.

Г. Камал

«Бәхетсез егет».

«Кәрим өчен бала — бала түгел, аның балада эше юк, ул үзен генә кайгырта һәм сату итүен генә белә. Комсызлык бөтен нәрсәне җиңә. Ул бер тиен өчен Галәви батрагын тиргәү генә түгел, баласын үтерергә дә хәзер тора торган кеше».

Г. Кашшаф.

Җәмилә — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисткасы — орденлы

ГӨЛСЕМ ХАНЫМ БОЛГАРСКАЯ

Җәмилә (*үз-үзенә, елаган тавыш белән).* Әй ходаем! ата-анасына изгелеге тияр, дип өмет итеп баланы үстер инде. Ике көннән бирле кайтканы юк. Белмим, кайда йөри торгандыр? Моннан элек тә, бер мәртәбә, шулай югалып, әллә нинди начарурыннарда йөреп, өч көндә йөз тәңкәдән артык акча бетереп кайткан иде. Атасы белән минем башыма хәсрәткә генә туган бала инде...

И алла! Үзе теләсә ни эшләсен иде шунда, аның өчен без монда кеше арасында бәднам булырга кирәк. Берсекөнгә әле менә Әхмәтҗан хаҗилардан бүләк багарга чакырганнар. Бармый калсаң бер дә генә ярамый: якын кеше, үпкәләүләре ихтимал. Барсаң тагы оят, кешенең күзе синдә генә була.

Г. Камал
Бәхетсез егет

Закир —Татар Дәүләт Академия театры артисты
Шакир Шамильский

«Закир, яхшы сәүдәгәр баласы буларак түгел, ә феодал һәм мещан башбаштаклыгын туктаусыз саклап килгән сәүдәгәр семьясы тәрбия иткән вәкил булып сәхнәгә чыга. Закир трагедиясе, яхшы кеше баласыннан кызганыч тормышы түгел, ә черек җәмгыять эчендә тагын да тирән булып мораль таркалган һәм шул черек сыйныфтан аерылып люмпинлыкка киткән сәүдәгәр баласының трагедиясеннән гыйбарәт».

Г. Халит.

«Ул үзенең тормышын аңлый. Ул шул ягы белән ата-аналарыннан өстен тора. Ләкин Закир тормышының ни өчен шушылай булуына төшенә алмый, гаепле кешене таба алмый. Ул «моннан котылырга миңа бер юл табарга кирәк» дип, котылу юлларын эзли. Ләкин таба алмыйча үзен-үзе үтерергә мәҗбүр була».

Г. Кашшаф.

Гайни — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисткасы

ФАТЫЙМА ИЛЬСКАЯ

Закир *(ямьсезрәк итеп).* Кемең килгән анда, яңа белешләреңме?

Гайни *(һәмишә ачулы).* Кем булсын, әни. Син барга күрә кермәде. Күршеләргә кереп китте. Бар кеше дә синең шикелле рөхсәтсез кеше өенә басып кермиләр.

Закир *(аяк тибеп).* Ялганлама! Йөзең кара, бәдбәхет! Әни дип ялганлап яткан буласың тагы! Кем килгәнен белмидер идем, ди.

Гайни. Белсәң, бик исем китә! Я бар! Күп сөйләп торма монда, үкчәңне күтәр! Моннан соң следың да булмасын! Кешене хатының, дип белдеңмени? Сүгеп яткан буласың! Бар моннан, вон! Бер минут та торма!

Закир *(бармакларын селкеп).* Мине куа алмассың, подлец! Беләсеңме син миңа пичә мең тәңкәгә төштең? Ә хәзер минем акчам беткәч, минем урыныма өеңә икенче кешеләр китерә башладыңмыни инде?

Гайни. Җикеренмә миңа! Минем үз йортым! Синең өең түгел. Үз йортым булгач, миңа теләсә кем килер, теләсә кем китәр. Анда синең эшең булмасын! Бар чык моннан! Бар, бар, бар! *(Закирны төрткәли.)*

Закир *(ачуын арттырып).* Якма кулыңны. Сөйләсе сүзең булса, болай гына сөйләш, мине алай тиз генә төрткәләп чыгара алмассың. Син бит, йөзең кара, миңа монда ни кадәр акчалар тоттырып китерүче!

Гайни *(мыскыл итеп).* Харап икән!

Закир. Син бит, патлец, биредә этиләр бар, анда баргач, сиңа барырмын, шунда никах укытырбыз, дип мине алдап килүче.

Гайни. Мин алдамадым сине, син үзең дегет лагоны шикелле тагылып йөрүче, сиңа соң эт барсынмыни?

Г. Камал
«Бәхетсез егет».

Гайни — атказанган артистка

САХИБҖАМАЛ ГЫЙЗЗАТУЛЛИНА-ВОЛЖСКАЯ

Гайни. И һи, һи, һи. Чынлап, Биби әби әйтсә дә, әйтмәсә дә, бик чибәр бит ? Мине нинди бай уллары да яратыр, бай кызларының да бер дә артык җирләре юк, авызларын җәлпәйтәләр дә, шулай итеп изелеп торалар (*мыскыл итеп күрсәтә.*) Биби әбидән сорамадым, Исмәгыйльнең аласы кызы нинди нәрсә дип, ул да шул бер изелгән арыш быламыгыдыр әле, бер дә артык җире булмас. Мин бай кызларын күп күргән инде. Берсенең дә искитәрлек җирләре юк.

Үзләре башларына энҗеле калфак кигән булалар. Никадәр алтын-көмеш нәрсәләр тагалар. Шулай да тәмам изелеп, җебеп торалар.

Г. Камал

«Бәхетсез егет».

Гайни—Т. Д. А. Т артисткасы

НИГЪМӘТУЛЛИНА

Мәрьям Сабитова — Т. Д. А. Т. артисткасы

Ф. КАМАЛОВА

Сәгыйт (*икенче городовойның кулында шкатулканы күреп, акрын гына).* И мескен! И бичара! Безнең өйгә кергән дә шул икән!

Кәрим *(Закирның гәүдәсе янына тезләнеп, бер кулын үзенең кулына альт бер җиңе белән күзләрен сөртеп).* И, бала, бала! Тәүфыйксызлык аркасында үзеңне дә, безне дә харап иттең!

Сәгыйт *(халыкка карап).* Дөньяда баланы бигрәк ата-ананың тәрбия кыла белмәве харап итә!!!

Г. Камал

«Бәхетсез егет».

Гайни — РСФСР ның атказанган, ТАССР нын халык артисткасы — орденлы

БОЛГАРСКАЯ

Сәгыйт Сабитов — ТАССР ның атказанган артисты

М. ИЛЬДАР

«Сәгыйт Сабитов, Кәрим бай кебек, тар карашлы, культурадан читтә торган тупас кеше түгел. Ул Россиядә промышленность капиталы үсеп пролетариат хәрәкәте башланган чорларда, татар сәүдә буржуазиясе арасында килеп чыккан яңару һәм җәдитчелек хәрәкәтенең вәкиле».

М. Гали.



Камали — ТАССР ның атказанган артисты

Х СӘЛИМҖАНОВ

Камали. Кулга акча төшкәндә, рәхәтләнеп тибеп бераз күңел юатып калмасак, башка һичбер шатланыр урыныбыз юк. Безнең күргән кадерсезлекләрне бер эт тә күрмәс. Безнең күргән кыенлыкларга адәм түгел, эт тә чыдамас. Аз гына нәрсә белән тотылып эләктең исә, чистый изеп бетергәнче кыйныйлар. Әле тик шул бары инде, көне-төне эчеп, исереп йөрү аркасында гына үз-үзеңне белешмичә йөрисең.

Г. Камал

«Бәхетсез егет».

«Бәхетсез егет» нең яңа басмасы сәхнә практикасы өчен дә әдәби таләпләргә җавап бирерлек итеп эшләнүе белән бергә, реалистик типларга һәм характерларга баетылган, аңарга яңа геройлар өстәлгән) геройларның мөнәсәбәте һәм сөйләү теле табигый индивидуальлеккә күтәрелгән».

Г. Халит.



.БЕРЕНЧЕ ТЕАТР « КОМЕДИЯСЫНЫН БЕРЕНЧЕ БАСМАСЫНЫҢ ТЫШЛЫГЫ

Казанда Харитонов матбагасында басылган.



«Беренче театр» ул үлми торган, яшәргә тиешле комедия».

Фатих Әмирхан.

«Рус тарихындагы шикелле үк, татар җәмгыятендә дә башланган яңа революцион чорның яңа художнигы татар буржуа-мещан семьяларының караңгы өй алларына, йозаклы булуларына карамастан, ватыпжимереп керә; кешелекнең матурлык омтылышына һөҗүм иткән мещан наданлыгын, башбаштаклыгын, вөҗдансызлыгын, ялганчылыгын, хәйләкәрлеген һәм тупаслыгын сәнгатьнең реалистик яктылыгы астында ачып күрсәтә».

Г. Халит.

Г. Камал татар әдәбиятында иң беренче комедия тудыручы дисәк тә ялгыш булмас. Ул комедия язуын «Беренче театр» белән башлап җибәрде һәм шуннан соң драмалар язу белән бергә, комедияләр язуны да бөтен гомере буенча ташламады. Ул үзенең бөтен табигате белән комедиягә, гомумән юморсатирага тартымлы кеше иде».

Х. Хәйри.

«Ул типлар билгеле бер чорның җимешләре булып килеп чыктылар, ул типлар татарның буржуа, мещан катлавына хас булган характерларда формалашып гәүдәләнделәр. Ул типлар татар халкының иҗтимагый һәм культура үсешләренә гаять дәрәҗәдә зарар китергән, татар халкы тарихында иң кабахәт караңгы тап булып торган социаль төркемнең вәкилләре булып гәүдәләнәләр».



«Беренче театр». Хәмзә бай — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисты — орденлы

ЗӘЙНИ СОЛТАНОВ

Хәмзә бай аңгыра түгел, ул бөтен семьяны үзенә генә каратып тотарлык «көчле» кеше. Шуның белән бергә ул коры «семьячы» гына да түгел, ул үзенчә «җәмәгать эшләренә» дә катнаша һәм шәһәрдә театр булдырмас өчен иренмичә «Җамалый унтер»дан алып губернаторга чаклы барып җитә».

Г. Кашшаф.

«Хәмзә бай тибы ул Г. Камал әсәрләренә генә түгел, бәлки бөтен татар әдәбиятында художество ягыннан гаҗәп зур осталык белән эшләнгән зур классик типларның берсе, ул безнең әдәбиятыбызда мәңгелек образ булып кала торган тип».

М. Гам.

«Хәмзә бай тибында, кадимче сәүдәгәрнең үзенә бер характерлы вәкиле — туып килүче демократик театраль сәнгатькә каршы һәртөрле чаралар эзләп тә, бер төрле дә конкрет эш чыгара алмаучы һәм прогрессив чаралар алдында көчсез булып чыдаша алмыйча, үзенең хурлыклы булуы көлкесе эчендә бетерелүче консерваторлар күренә.

Хәмзә бай образында һәртөрле тәрбия һәм культура чараларын үз семьясына кертмәс өчен аякланган һәм һәрбер төрле яңалык элементларын таныргa теләмәгән тискәре сәүдәгәр гәүдәләндерелә».

Г. Халит.

Гафифә. Мин аны кияр идем киюен дә, аның шул җиңнәре сак җиң. Килешмәс. Үзең дә, ичмасам, бер кеше төсле чибәр күлмәклек алып биргәнең дә юк. Бер җиргә бара башладың исә, киеп барырлык һичбер юньле матур күлмәгем юк.

Вәли. Соң бит инде аны хәзер генә тегеп булмый лабаса, фу алла! Бар икән кылану, анысы да ярамый, монысы да ярамый, белмим боларга нәрсә генә ярый торгандыр, чәнчелеп бетегез шунда, сезне көтеп уеннан калыр хәлем юк. *(Чыгып китә башлый.)*

Г. Камал
«Беренче театр».

Вәли — Т. Д. А. Т. артисты
И. *ГА ФУРОВ.*
Гафифә — Мамадыш колхоз театры артисткасы
ГОБӘЙДУЛЛИНА



Вәли — ТАССР ның атказанган артисты
Х *СӘЛИМҖАНОВ*

Гафифә өчен театр кебек бер культура күренеше дә, сәхнәгә чыкканнарны карау түгел, бәлки үзен сәхнәгә чыгару, үзенең күлмәген күрсәтү белән ләззәтләнү һәм купшылыгы белән кәпрәю урыны булып тора».

Г. Халит.

Хәмзә байның кияве Вәли белән килене Факиһә, нәсел һәм кан ягыннан Хәмзә байга һичбер мөнәсәбәтләре юк. Алар шул чордагы тормыш шартларының мәҗбүр итүе аркасында, соңыннан Хәмзә бай семьясына килеп кушылырга мәҗбүр булганнар».

М. Гали.

Вәли — ТАССР ның атказанган артисты
КАМАЛ III

«Аның аңгыралыгы безгә бөтен тулылыгы белән килеп баса. Ләкин ул аңгыралык, Хәбибрахманның, фәкать үзенә генә хас булган аңгыралыгы түгел, ул—иске фикерле, бозык карашлы, тупас, комсыз, үзеннән дә зур кеше юк дип йөрүче аңгыра байларның җимеше булып килеп чыга. Хәбибрахман — кадимчелекнең чиге. Аның аңгыралыгы — феодализмга, реакцион идеологиягә нигезләнгән».

Г. Кашшаф.

Хәбибрахман — артист
КОЛМӘМӘТ

Факиһә — РСФСР ның
атказанган артисткасы —орденлы
Г. БОЛГАГСКАЯ

Хәбибрахман *(кулларын селтәп).* Бармыйм дигәч бармыйм инде! Иң әвәл мин аның, ул театрның кайда икәнен белмим.

Факиһә *(мыскыл итеп бармакларын бөкләп санарга керешә).* Бу булды бер!

Х ә б и б р а х м а н. Икенчеләй, кайдан керәсен, ничек керәсен белмим.

Факиһә. Ике, өч.

Хәбибрахман. Анда кергәч тә нинди урынга утырырга?

Факиһә. Шуның белән була дүрт! Зинһар ичмаса инде эчендәге бар серләреңне сөйләп бетереп кешене көлдермә, кеше ишетсә «моның белгән нәрсәсе бар микән» ди башларлар. Кеше җаен тапканны без генә табарбыз әле.

Хәбибрахман. Кирәкми, бармыйбыз; мин куркам.

Факиһә. Чү, чү, куркуыңнан егылып китә күрмә! Шул кадәр зур гәүдәң белән куркам дип әйтергә сиңа кешедән оят!

Хәбибрахман. Кирәкми, бармыйм!

Г. Камал
«Беренче театр».

Хәбибрахман, Факиһә

Факиһә — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисткасы

ФАТЫЙМА ИЛЬСКАЯ

Биби — ТАССР ның атказанган артисткасы

МӘРЬЯМ СУЛЬВА

Биби. Үзләре юньләп йомыш куша белмиләр дә, кешене орышалар. (*Чәй урыны хәзерли, өстәлнең почмагына самовар, поднос, аның янына зәңгәр эмалированная полоскательница куя.)* Көне-төне эшлисең дә эшлисең, аның өстенә тагын һәр көн орыш та талаш. Миңа дисә кырык чөйләре кырылып бетсен шунда. Хәбибрахман абыйларның да, Гафифә апаларның да театрга киткәннәрен әйтәм. Мине генә орышмасын әле, аларны да орышсын.

Г. Камал

«Беренче театр».

«Г. Камал буржуа черекләреннән, печән базары «геройларыннан ачы итеп көлде, ләкин хезмәт ияләре вәкилләреннән һичбер вакытта да көлмәде. Аның әсәрләрендә асрауларнын. ялчыларның, конторщикларның байларда изелгән, кимсетелгән хәлдә яшәүләре күрсәтелә».

Х. Хәйри

Хәмидә — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисткасы «Хезмәт батырлыгы өчен» медале белән бүләкләнгән

Н. ТАҖДАРОВА

Әхмәтҗан — ТАССР ның халык артисты

КАСЫЙМ ШАМИЛЬ

Хәмидә. Баланы егерме ел үстереп тә бер юньле яхшы бирнә дә киеп калмагач, дөньяда торганың ни дә, тормаганың ни? Әнә Гыйльми Бәдринең кызы бик чибәр дә бит, матурлыгына карап алып булмый шул. Аларның юньле бирнә бирәселәре дә юк, күп булса бер асыл бирнә бирерләр. Кодагый булган кешенең ашлы-сулы, бай булганы күңелле. Улыңны өйләндереп тә бер рәхәтләнеп кунакка йөреп калмагач, дөньяның ни рәхәте бар, дөнья ике килми ул.

Г. Камал

«Бүләк өчен».

Бүләк өчен» комедиясендә без Хәмидәнең фикерләре нәрсәдән торганын ачык күрәбез. Ул да, фәкать «бирнә күлмәге кияр өчен генә» улына бай җирдән кыз алырга тырышып йөри, чөнки «баланы егерме ел үстереп тә бер юньле, яхшы бирнә дә киеп калмагач, дөньяда торганың ни дә, тормаганың ни... Кодыгай булган кешенең ашлы-сулы, бай булганы күңелле. Улыңны өйләндереп тә бер рәхәтләнеп кунакка йөреп калмагач, дөньяның ни рәхәте бар, дөнья ике килми ул». Хәмидәнең бу сүзләре мещан хатын-кызларының тормышка ничек карауларын ачык әйтәләр. Аларча тормышның барлык яме — әнә шул аш-су мәҗлесе. Туган бала да шул аш-су өчен корбан ителә!..»

Г. Кашшаф.

«Хәмидә үзенә күбрәк бүләк алырга теләп, улын теләсә нинди ахмакка ир итәргә хәзер; Хәмидә туй өчен үз кесәсеннән мал чыгармаячак, чөнки ул үзен бер хосусый милекче рәвешендә иренә каршы куя... Әхмәтҗан үз баласының семья проблемасын хәл кылуга килгәндә дә, моның нигезендә иң элек акчаның үз кесәсеннән ничек чыгарга тиешлеген куеп карый».

Г. Халит.

Габдуллаҗан — Т. Д. А. Т. артисты

Ш. МӘҖИТЕВ

Габдуллаҗан. Кодагыең эшнең җаен белсә, мин дә бик яхшы белдем инде. Син үзеңә асыл бирнәләр килсен өчен, минем башымны колга, телеграм баганасы, тагын әллә нәрсә шикелле озын, ямьсез, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы бер кызга бәйләмәкче булган икәнсең. Юк инде, хәзер торып тор, ул эшләр бик тиз генә эләкмәс! Хуш, сау булыгыз. *(Ишекне бик каты ябып чыгып китә)*

Әхмәтҗан. Рәхмәт анасы, рәхмәт, мине дә күн акча тотудан коткардың. *(Чыгып китә)*

Хәмидә *(югары карап, елаган тавыш белән).* Әй алла нинди гөнаһ шомлыкларым булды икән. Тәмам булган эшне тараттым.

Мәхүп *(халыкка карап елаган тавыш белән).* Монда иң бәхетсез кеше мин! *(Хәмидәне төртеп күрсәтеп)* Шушы юләрнең тик тормас теле аркасында, ничә күлмәклекләрдән, илле-алтмыш тәңкә садака-хәер акчаларыннан коры калдым.

Г. Камал

«Бүләк өчен»

Сәрвиҗамал — РСФСР ның атказанган артисткасы — орденлы

Г. БОЛГАРСКАЯ

Сәрбиҗамал. Әй раббем! Нихәл итим, күз алдымнан әллә нинди кара нәрсәләр йөри. Һәммәсе дә әллә нинди мин белмәгән, мин ишетмәгән сүзләр сөйлиләр. Куркам, әллә нигә куркам. Бу эшләрнең ахыры бер дә хәерле булмас төсле күренә. Кешеләре дә әллә нинди куркыныч, сүзләре әллә нинди ямьсез. Әнвәр тиз генә никах укытса, тиз генә бу пычрак көннәрдән котылсам... Һи алла! (*Елый.*) Ичмаса Мәгълифә карчык та килми. Хәер килсә дә аннан да бер тиен дә файда юк. Конарсыз карчык. Күзләре үк әллә нинди куркыныч. Йөзенең өстендә каралар уйнап тора.

Г. Камал
«Уйнаш».

Әнвәр — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисты — орденлы

З. СОЛТАНОВ

Мәгълифә — ТАССР ның атказанган артисткасы

НА ФИГА АРАПОВА

Мәгълифә. Чыгам, чыгам. Кумасаң да чыгам. Ачыккач үзең үк. чакырып китерерсең әле. Авызыңа салган сары майны хәзер йота белмәсәң, соңыннан үзең телләреңне салындырып җалманып йөрерсең әле. Кискән ИКМӘК кире ябышмый ул. Бер сөрелгәч ӘЛЛӘ кайда КИТӘ алмассың. *(Тавышын үзгәртеп истиһза кылып.)* Елама, кызым, елама, юри генә әйттем. Кирәк булганда мине ташлама, чакырт. Әптерәшиттән чибәрләрне дә табып бирермен. Хуш, сау бул! *(Истиһза кылып көлә.)* Һи-Һи-Һи. *(Чыгып китә.)*

Сәрбиҗамал. Бәдбәхет убыр! Дәҗҗал. *(Диванга капланып елый.)*

Г. Камао

«Уйнаш».

Әнвәр *(урыныннан торып).* Кирәге дә юк! Дөньяда чибәр син генә түгел! *(Тартманы кесәсенә сала.)* Алай бик чәпчемә.

Сәрбиҗамал. Алланың каһәре төшсен сезгә... җир йотсын... сезне... *(Елый, диванга егыла.)*

Әнвәр. Чәнчел, Кадал! *(Кукрәгенә сугып).* Бу кесәдә акча бетмиче кыз бетмәс! *(Ишекне каты ябып чыгып китә)*

Сәрбиҗамал. Аһ, аһ, аһ, аһ! *(Егыла тавышы бетә.)*

Г. Камал

«Уйнаш».

Мәгълифә ул драмада иң яхшы эшләнгән образ. Г. Камал әсәрләрендә бирелгән бу тип карчыклар арасында үзенең художество ягыннан эшләнүе белән Мәгълифә һич шиксез иң югары урынны тота.

«Бозык Әнвәр-мещан сәүдәгәр җәмгыятенең женси түбәнчелеккә киткән моралеп — проституцияне үзенә профессия иткән типлардан».

Г. Халит

Маклер Фәтхерахман — Т. Д. А. Т. артисты

ШАКИР ШАМИЛЬСКИЙ

Әптери — ТАССР ның атказанган артисты

М. ИЛЬДАР

Әхмәтҗан — Т. Д. А. Т. артисты

С. БУЛАТОВ

Фәтхерахман. Узган ел яхшы гына тәти кошлар тозакка эләккәннәр иде. «Шәһәргә даныңны чыгарам» дип куркытып егеттән, «егет белән йөргәнеңне иреңә әйтәм, хат язып җибәрәм» дип хатыннан шактый гына кубарган идем. Һәм чыннан да әгәр икесе дә йөзәр сум тамызмаган булсалар, чынлап та кеше арасына исемнәрен чыгарачак идем, ярый әле биреп котылдылар. Миңа: «Син ник бу елларны Мәкәрҗәгә бармыйсың?» диләр. Тик торып ике йөз тәңкә акча төшерерлек булганда пычагымамыни миңа Мәкәрҗә? Кадрен белгән кешегә безнең Мәкәрҗә өсте үзе бер зур ярмарка.

Г. Камал

«Уйнаш».

Әхмәтҗан. Уф алла! Көчкә котылдым. Менә син бәдбәхетләр. Әле ярый син яхшылык итеп хат яздың. Әгәр син белдермәгән булсаң гомерем буенча белмиче шул урам себеркесе белән гомеремне уздырган булыр идем бит. Синең хатыңны алгач хафамнан өч көн эчендә ун еллык картайдым. Рәхмәт, Фәтхерахман, сиңа рәхмәт. Мине зур бәладән коткардың, сине ничек кенә итеп сыйлыйм икән инде.

Фәтхерахман. Юк, Әхмәтҗан, мин сыйлану өчен, я булмаса акча өчен бу эшне эшләмәдем. Бары тик аларның йөз каралыкларын дөньяга чыксын дип, алла ризасы өчен эшләдем.

Әхмәтҗан. Рәхмәт, Фәтхерахман, рәхмәт!

Әнвәр тәрәзәдән сикереп кереп, ишектән йөгереп чыгып китә.

Әхмәтҗан *(Әнвәрне күреп).* Һай йөзе кара, бәдбәхет! Тот!

Фәтхерахман. Тот! Сип!

Г. Камал

«Уйнаш».

Әптери. Кая морза, баш авырта, яртыны сындырыйм әле.

Интеллигент. Нахал, сабакы! *(Тиз генә китә башлый.)*

Фәтхерахман утырган урыннан торып күздән югала.

Әптери. Ну алай булса бер тәмәке бир.

Интеллигент. Хулиган. *(Кача башлый.)*

Әптери *(яңадан җиңнәрен тартып).* Давай дим егерме тиен. Ату...

Интеллигент. Городовой!!! *(Әптери кача башлый. Интеллигент тиз генә күздән югала.)*

Әптери *(мәкруһ тавыш белән мыскыл итеп).* Городовой! Тапканнар кычкырырга бер сүз. Ну киреләр соң шул җәдитләр, һич берсеннән бер тиен алыр хәл юк.

Г. Камал

«Уйнаш»,



تیاترو مجموعه‌سی

جلد: ١١ — کتاب: ١٣

« بانکروت »

پیه‌سه ٣ پرده‌ده

علی اصغر کمال

ناشرلری:

احمدگرای حسنی وشرکاسی

قزان.

Казань.
Лито-Типографія И. Н. Харитонова.
1912.

بهاسی ٢٠ تین

«БАНКРОТ» ПЬЕСАСЫНЫҢ ТЫШЛЫГЫ

1912 нче ел Казанда Харитонов матбагасында басылган



«БАНКРОТ». СИРАҖЕТДИННЕҢ ӨЙ ЭЧЕ КҮРЕНЕШЕ. Т. Д. А. Т. ПОСТАНОВКАСЫ

«Кадимче татар сәүдәгәренең кыргыйлыгы һәм кешелексез тупаслыгы монда өстенлек ала. Банкротлашу хәйләсен ул ахмаклану махинациясе белән үткәрү юлына төшә. Бу инде кадимче сәүдәгәрнең-мещанның иң соңгы оятсызлыгы һәм, кеше малын үзендә калдыру өчен, кешелектән чыгып акылдан язу хәленә керүе».

Г. Халит.

«Банкрот» һәм «Безнең шәһәрнең серләре» Г. Камалның һәм гомумән татар драматургиясенең иң көчле комедияләре».

Х. Хәйри.

«Банкрот» Г. Камалның гаять мастерларча язылган һәм сюжетлы комедияләреннән берсе».

М. Гали.

«Г. Камал көлүнең көчен, аның социаль функциясен яхшы аңлый иде. Ул көлү коралын иске тормышка, дошманнарга каршы бик оста файдаланды».

Х. Хәйри,

«Сиражетдин тибы — капиталистик тормышка ярашып эш итә торган, ләкин шул тормышның бару формаларын аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган кадимче тип.

Сиражетдин — семьячы да, җәмәгатьче дә түгел. Ул андый эшләрдән ерак тора. Ул бары «бер тиен» табу турында гына уйлана, шул эш өчен иң кабахәт эш эшләргә дә хәзер тора».

Г. Кашшаф.

Сиражҗетдин — РСФСР ның атказанган артисты

Х. ӘБҖӘЛИЛЕВ

Сиражҗетдин *(ишектән кызуланып кайтып керә, өстен чишенеп ташлап').* Һәммәсе дә мин теләгәнчә булды. Барысына да бишәр йөз сумлык акчалар алдым. «Андый акчалар ни эшкә кирәк соң алар?» диләр. «Акчаны үзем белән алып барам, шуның өчен кирәк» дигән булам. Фидыр Иванич әйтә: «Айһай, Сиражҗетдин Гыйлаҗеттинович, хата кыласың икән. Хәзерге заманнарда акчаны үзең белән йөртү апасны бит, перават белән генә җибәрергә кирәк иде» ди. *(Өстәл тартмасыннан әллә нәрсә эзли.)* «Ничава» дим, «алла кушмаган эш булмас» дим. «Мин бит мөселман кеше» дим. «Мөселман кеше ул андый юк-бар эштән курыкмый дим. Миңа нигә куркырга. Аны кладавайдагы тимер сандыкта кем килеп урлый ала. *(Өстәл тартмасыннан ачкыч алып, саквояжны шкафка куеп, кесәләрендәге акчаларны бераз чыгарып яңадан тыгып куеп.)* әйдәгез әле сез, акчалар, мин кайтканчы кладавайда бик һәйбәтләп тынычлап кына ятып торыгыз әле. Эшне төзәтергә бәлки сез артыгы белән җитеп торырсыз. *(Чыгып китә)*

Г. Камал
«Банкрот».

«Сиражи Туктагаев «тыштан караганда бик суфый күренә торган сәүдәгәр», ә асылда ул жулик, аферист, комсыз бер кеше. Ул башын диванага салып үзен банкротлыкка чыгара, шулай итеп Мәскәү байларын алдый, үзенә байлык җыя. Ул үз кесәсе интересыннан башканы белми, «ата-бабаларча» эш итәм дигән булып, төрле кабахәтлекләр эшләүдән дә тартынмый. Тыштан гына «суфый» булып күренергә тырышкан чын йөзе әнә шундый икәнлеге «Банкрот»та бик оста күрсәтелә».

Х, Хәйри



«Туганым», «Гарифә», «Мәликә» — Т. Д. А. Т. артисткалары

М. ШӘРИПОВА, АИГАШ МИҢЛЕБАЕВА

Гарифә *(Мәликә белән ишектән кереп түргә утырып),* син ишеттеңме? Алар анда нәрсә пыш-пыш сөйләшәләр?

Мәликә. Юк, мин ишетмәдем. Мин кергәч шып туктадылар.

Гарифә. Мин кергәч тә шулай иттеләр. Әллә нәрсә «бламажый» дигән сүзләрен генә ишетеп калдым. Я бламажыйлары оемагандыр әле, я җилемен аз салганнардыр.

Мәликә. Бламажыйлары оемаган дигәннән исемә төште, бер көннәрне мин чүпче Әхмәтләргә кунакка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй пычкылдап тора.

Гарифә. Андый була ул, әнә бер көнне мин читекче Таҗиларга чәйгә барган идем, кабарткан паштитлары менә нәкъ такта шикелле булган. Бөтенләй менә үзе такта шикелле, үзе ике куллап сындырып булмаслык каты булган иде.

Мәликә. Читекче Таҗи дигәннән исемә төште әле, аларның бер шадра кызлары бар иде, ончы Шакир улына кияүгә биргәннәр иде, ишеткәнең бармы, чибәр торалармы икән?

Г а р и ф ә. Белмим, чибәрдер, сорашканым юк, каенанасының сүзен бер дә тыңламый диләр.

Мәликә. Каенанасының сүзен бер дә тыңламый дигәннән исемә төште әле, син ишетмәдеңме, тегүче Әхмәдулла хатынын аерган диләр, чын сүз микән?

Гарифә. Чын булырга кирәк, бер көнне югары урамга кибеткә чыкканда күргән идем, кулына кәрҗинкә тотып, бәрәңге алып йөридер иде.

Мәликә. Бәрәңге димәктән безнең дә кәбестә тозлыйсы бар иде әле, алдырырга һич тә җитешә алганым юк, сез тозладыгызмы?

Гарифә. Тозладык, алма белән карбыз да тозладык, кәбестәләр бик һәйбәт туры килде.

Гөлҗиһан —
Т. Д, А. Т. артисткасы

Ф. КАМАЛОВА

«Г. Камал, буржуа-мещан хатын-кызларының аңгыра икәнлекләрен күп кенә комедияләрендә күрсәтте. Аларның ак белән караны аера алмаслык дәрәҗәдә тупаслануларын ачып салды, наданлыкларын, культурасызлыкларын фаш итте, җәмгыятьнең алга китүенә комачаулап торуларын, җәмгыять өчен зарарлы булулыкларын әйтте. Г. Камал бай хатын-кызларын кайда очратырга мөмкин булса, шул урында, шул обстановкада бирә. Аларны без бала тәрбияләү Эшендә дә, аш-су мәҗлесләрендә дә күп күрәбез. Болар һәркайсы тар карашлы, чикләнгән фикерле кешеләр. Алар барысы да үзләреннән дә зур кеше юк, дип, үзләреннән дә акыллырак кешеләр юк, дип йөрүчеләр. Болар барысы да югарыда күреп узган «мөгътәбәр» бай кадимчеләрнең үзләренә тиң булырлык курчаклары».

Г. Кашшаф.

Гөлҗиһан — РСФСР ның атказанган артисткасы — орденлы

Г. БОЛГАРСКАЯ

«Геройларның социаль характерларын үзенчәлекле итеп ачудан бигрәк, монда аларның бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрен һәм карашларын шул тәрбия тирәсендә күрсәтергә тырышу урын ала».

Г. Халит.

Гөлҗиһан — ТАССР ның атказанган артисткасы

М. СУЛЬВА

Гарифә — Т. Д. А. Т. артисткасы

Ф. КАМАЛОВА

СИРАҖЕТДИН, ГӨЛҖИҺАН, НӘГЫЙМӘ КАРЧЫК
(1 нче пәрдә)

СИРАҖЕТДИННЕ МОСКВАГА ОЗАТУ КҮРЕНЕШЕ
(1 нче пәрдә)

I НЧЕ ПӘРДӘНЕҢ ФИНАЛЫ

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘДӘН КҮРЕНЕШ

Нәгыймә карчык — ТАССР ның атказанган артисткасы

ВАФИГА АРАПОВА.

НӘГЫЙМӘ *(ишектән чирекле шешә белән саргылт төстә сыек нәрсә күтәреп кереп)* Уф алла, арып беттем. *(Шешәне урындыкка куеп башыннан шәлен сала.)* Бүгенге мәҗлескә килгәнче тизрәк өлгерсен дип алып килдем. *(Шешәне селкетеп.)* Йөзе кара, бер дә күбекләнми. Тизрәк ачысын, тизрәк төнәсен дип трахтир сырасын ике шешә итеп салган идем, алай да әле әчеп җитмәгән. Монысы кыйммәткә төште: егерме тиенгә тамыр алдым, жике шешә трактир сырасы, ярты кадак шикәр салдым. Мин кайнаткан тамырны бай хатыннары бик яраталар. «Синең кулың бик шифалы, эчеп жибәргәч тә бөтен тамырларга китә, тәмам изелдереп йоклата» диләр.

Трахтир сырасын күбрәк салсаң, аның өстенә актан да бераз тамызсан йоклату гына түгел җырлатыр да ул. *(Шешәне алып)* Тукта әле моны кая булса да бер җиргә яшереп куярга кирәк. Я кунакларыниләре килеп күрерләр. Бай хатыннары алар бер дә серләрен кешегә сиздерәселәре килми. *(Шешәне диван астына яшереп)*

Аларның баш ярылса бүрек эчендә, кул сынса җиң эчендә була. *(Икенче ишектән чыгып китә)*

Г. Камал

«Банкрот».

«Туганым» — Т. Д. А. Т. артисткасы

Р. ЖИҺАНШИНА

Сираҗетдин — РСФСР ның атказанган артисты

Х *ӘБҖӘЛИЛЕВ*

Мөхәммәтҗан I —

БАРИЕВ

Хәдичә — Т. Д. А. Т. артисткасы
- Г. КАМСКАЯ

Мөхәммәтҗан I — Т. Д. Л. Т. артисты
БАРИЕВ

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘДӘН КҮРЕНЕШ

Гарәфи — Т. Д. А. Т. артисты
НӘҖИП КАСИМОВ

Кибетче малай Мөхәммәтҗан II —
Т. Д. А. Т. артисты *ЗАКИРОВ*
Асрау кыз — *БАСЫЙРОВА*



Сиражетдиннең агасы Җамалетдин — артист
ХӘМИТ КОЛМӘМӘТ

Камалетдин — Т. Д. А. Т. артисты
ХӘБИБОВ

Сиражҫетдин — Караул талыйлар

«Банкрот» һәм «Безнең шәһәрнең серләре» Г. Камалның һәм гомумән татар драматургиясенең иң көчле комедияләре».

Х. Хәйри.

«Банкрот» Г. Камалның гаять мастерларча язылган һәм сюжетлы комедияләреннән берсе».

М, Гали.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘДӘН КҮРЕНЕШ

3 НЧВ ПӘРДӘДӘН КҮРЕНЕШ



Гарәфи. Моны күргәч тә минем йөрәкләрем «гөп» итен китте, кондуктор да; «Князьне талаганнар» диде.

КОМЕДИЯПЕҢ ФИНАЛЫ



Доктор — Т, Д. А. Т, артисты
Н. ГАЙНУЛЛИН

Сиражетдин. Палпсәйски! Караул! Талыйлар!

Василий Дмитриевич *(Доверенныйларын карап).* **Алай булгач, әфәнделәр, безгә эшкә керешергә вакыт. Сез ни дисез?**

Бәдигыльҗамал — ТАССРның атказанган артисткасы

М. СУЛЬВА

Гөлҗамал — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисткасы

Н. *ТАҖДАРОВА*

Бәдигыльҗамал *(кереп скамьяларны рәтләгән булып).* Мәхәббәтсез, тәмам саруымны кайнатып бетерде инде. Ибраһим кайтты исә, шуның белән чукыр, чукыр чукырдашалар. Һәрвакыт тезгә тез куешып утыралар да эҗе дә гөҗе киләләр. Ибраһимның тәмам башын әйләндереп бетерде инде. Кайдан алдык шул нәрсәне.

Г. Камал

«Кайниш».

«Г. Камал үзенен бу әсәрендә буржуа-мещан семьясында кайниш мәсьәләсенең торышын күрсәтә. Бәдигыльҗамал улы белән килене арасын бозыштыруда дөньяда булган бөтен начарлыкларны эшләүдән кире тормага Бәдигыльжамал тибындагы каенанага нинди яхшы килен булганда да ошарга һәм түзеп торырга мөмкин түгел».

М *Гали.*

Зәйнәп — РСФСР ның атказанган, ТАССР ның халык артисткасы — орденлы

Г. БОЛГАРСКАЯ



Ибраһим — ТАССР ның атказанган артисты

М. ИЛЬДАР

Зәйнәп. Ярабби ходаем, бу нинди бәлә!!! Бу нинди бөһтан!!! *(Елый.)*

Ибраһим. Ела, ела, күзләрең чыкканчы ела, мине елап ышандыра алмассың. Син мине җиде елдан бирле алдап йөрткән икәнсең, син мине җиде елдан бирле мәсхәрә кылып өстемнән икенче кеше белән йөреп, аннан булган баланы минем өстемә тагып йөргән икәнсең. Син бәдбәхет икән, син ялганчы икән. Җиде ел мине сөям дип алдаган икәнсең!

Зәйнәп. Алла хакы өчен дип әйтәм, миңа бөһтан бәләләр якма... *(Елый.)*

Ибраһим. Бөһтан. Әллә шаһите дә кирәкме? Мә кирәк булса укы! *(Хатны битенә ыргытып бәрә.)*

Зәйнәп *(хатны алып укып кулыннан төшереп җибәрә дә урындыкка егылып).* Әй раббем! Бар икән күрәселәрем! *(Елый.)*

Ибраһим *(хатны алып кесәсенә салып идән буенча йөреп).* Хәзер инде син миңа кирәк түгел! Үзең дә кирәк түгел, балаң да кирәк түгел. Төялегез дә китегез. Уйнашчың белән бергә рәхәтләнеп торырсың.

Зәйнәп. Ибраһим җаным, зинһар мине болай хур итмә. Икебез дә хур булабыз. Валлаһи минем бер гөнаһым да юк, дошман сүзенә карап алданасың! *(Елый.)*

Ибраһим. Мин алданасын алданган инде, җитәрлек алданган. Мине антларың, елауларың белән генә ышандыра алмассың! Хуш, сау бул. *(Өстене киенә, чыгып китә, Зәйнәп кычкырып елап кала.)*

Г. Камал

«Кайниш».



Татар театрының бөек хезмәтчесе Галиәсгар абзый Камал!

Татар әдәбияты иң түбән баскычта һәм татар театрының бөтенләй юк вакытында үзегезнең көчле язу талантыгыз белән мәйданга чыгып, татар дөньясында беренче мәртәбә искелеккә, көфер почмагына татар хатыннарының тоткынлыгына каршы көрәш ачып әдәбиятыбызга яңалыклар тудыручы һәм туачак театрыбызга, даһи Кариевка репертуар хәзерләүче Сез булдыгыз. Татар театрына иң күп көч куючы, аның репертуарын аксатмый алып баручы Сез идегез. Аның белән калмый, Сез өзелеп сөйгән сәхнәгә кереп, уйнавыгыз сәхнә сәнгатен никадәр яратуыгызны күрсәтә. Сәхнә галәмендә каләм көче белән күп хезмәт итүче сөекле абзабыз Галиәсгар Камалны бүгенге сәхнә бәйрәме белән котлап, тагы да сәхнәгә күп яңалыклар тудыруын, озак хезмәтен теләп, шул кечкенә бүләкне тәкъдим итәбез.

«Дәүләт театр артистлары»

1

ТӨЗӘТҮ

Бит	Юл	Басылган	Укырга
92	Өстән 9	карпевка	Кариевка

Заказ 55

1924 нче ел Г. Камалның сәхнә бәйрәмендә Дәүләт театр артистлары тарафыннан бирелгән адрес.

Шкафчы Әхмәтҗан — ТАССР ның халык артисты

К. ШАМИЛЬ

«Кадимчелекнең чишмәсе — Печән базарындагы «көфер почмагына» кайтып кала. Аида гайбәтче, әфиунчы Әхмәтҗан бар һәм ул барлык кадимчеләргә көч биреп тора. Әхмәтҗан урамнан узган-барган һәрбер кешегә эт кебек өреп кала, ул узып баручыдан үзенчә көлә, аларны мыскыл итә һәм шул эшен «мөселманлыкка» зур хезмәт күрсәтү дип уйлый. Әхмәтҗанны карап торучылар аның аңгыра хәрәкәтләреннән көлмиләр, киресенчә, авы изгелек дип кабул итәләр, бу эшләрнең «әҗерен оҗмахта күрүенә» ышаналар. Бөтен начарлык, бөтен бозыклык һәм аңгыралык әнә шул «көфер почмагыннан», аның җитәкчесе — Әхмәтҗаннан тарала. Алар җәмгыятьне агулаучылар, җәмгыятьнең һавасын бозучылар булып торалар...

Әхмәтҗан — иҗтимагый тормышның атмосферасын сәламәтләндерүче һавадан курка, аның белән көрәшә, сасыган, тончыктыргыч тормыштан аерылмас өчен барлык мөмкинлекләрдән файдалана. Дөрес, бу иске фикерле, бозык карашлы, сәламәтләнмәслек дәрәҗәдә агуланган кадимчеләрнең көрәш методлары бик примитив, бик зәгыйф, тәнкыйтьтән түбән бер юл белән бара, ләкин шулай булуга карамастан. алар хезмәт ияләренең фикер үсешләренә киртә булып торалар, алар алга баруны туктаталар, кешенең инициативасын буалар».

ГАЛИӘСГАР КАМАЛ

1раматург Галиәсгар Камал образы—
Т. Д. А. Т. артисты

ГАБДРАХМАН КАМАЛ П

Хәсән. Рәхим итегез; Галиәсгар әфәнде, утырыгыз.

Камал. Рәхмәт, утырып тормыйм. Сезгә, Габдулла әфәнде Тукаевның наширләренә, әйтәсе бер генә сүзем бар.

Барда. Җә, җә.

Камал. Габдулла әфәнде бик җидди авыру.

Барда. Булмас ла, ай алла, никадәр тәәссеф, ничек авырый, ни белән авырый?

Камал. Даими авыру белән. Сез аны бик яхшы беләсез, нигә сорыйсыз?

Хәсән. Анысы дөрес, Габдулла әфәнде күкрәк хәстәсе белән интегә иде.

Камал. Хәзер ул кан төкерә.

Барда. Ах бичара! Дәваларга кирәк үзен, доктор чакырырга кирәк.

Камал. Мин доктор чакырттым. Доктор Тукайны Көньякка диңгез буена җибәрергә куша, шуның өчен... акча кирәк. Габдулла әфәнде соң дәрәҗәдә ярлы... Габдулла әфәнденең китаплары меңнәр, миллионнар

«ТУКАЙ° ПЬЕСАСЫННАН КҮРЕНЕШ

ОБРАЗЫ СӘХНӘДӘ

ясый, ә шагыйрь кесәсенә шуның тиеннәре генә керә, Тукай ачлы-туклы.

Хәсән. Дөрес әфәнделәр, Галиәсгар әфәнде мәсьәләне бик вакытлы куйды.

Камал. Юк, үкенечкә каршы мин моны бик соң куйдым.

Камал. Әфәнделәр, мин сезнең бу сценаны башта комедия генә дип торган идем, траги-комедия булып чыкты бу, сез нәрсә уйлыйсыз? Сүз, Габдулла әфәнденең гомере, яшәве турында бара бит, сез беләсезме шуны? Ул сезгә биргән йөз меңнәрнең бер, я ике меңен генә кайтарыгыз һич булмаса үзенә, кирәкми сезнең жаныгыздан суырылып алынган 5—10 сумнарыгыз, мин моны үзем дә чыгарып бирә алам.

Камал. Сезнең берегездә дә намус юк. Менә ни өчен тыныч сез. Ләкин бер көн килер... Сез безнең чергән күкрәк һәм аркаларыбызга чыккан бөкреләр хисабына җыйган меңнәр, миллионнарыгызны кире косарсыз. Бу көн ерак түгел.

Әхмәт Фәйзи «Тукай»,

Драматург Галпәсгар Камал образы— Т. Д. А. Т. артисты

НӘҖИП ГАЙНУЛЛИН

«ТУКАЙ», ПЬЕСАСЫННАН КҮРЕНЕШ

Халык шагыйре Габдулла Тукайның «Ысул кадимче» исемле шигыре буенча Г. Камал тарафыннан язылган «Ысул кадимче» сатирасының беренче картинасы

Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры куелышында

«ЫСУЛ КАДИМЧЕ» САТИРАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ КАРТИНАСЫ

«ЫСУЛ КАДИМЧЕ» САТИРАСЫНЫҢ ИКЕНЧЕ КАРТИНАСЫ



ГАЛИӘСГАР КАМАЛ—

Клуб сәхнәләрендә куелган һәм куелып килә торган аның уннарча инсценировкалары бар. Г. Камал заем тарату кампаниясенә карата да, бишьеллык планны дүрт елда төгәлләү турында да инсценировкалар язды.

«Халык дошманнары, контрреволюцион буржуаз милләтчеләр, Г. Камал үзенең әсәрләрендә татар буржуа тормышындагы феодалчылык калдыкларын тәнкыйтьләгәндә, ул либераль буржуа карашында торып, буржуа тормышының кимчелекләрен төзәтү өчен генә тәнкыйтьләде дип күрсәтергә маташтылар. Алар, татар халкының яраткан —

АРТИСТ МАМАЙ ЁЩМ ХАЛИТОВ Г. КАМАЛНЫҢ «ХАТЫЙН —ЛАТЫЙН » КУПЛЕТЫН СӨЙЛИЛӘР

— атаклы драматургы иҗатынын революциягә кадәр үк прогрессив роль уйнаганлыгын, татар театры, драматургия үсеше тарихында аның әһәмиятле урын тотканлыгын инкяр итәргә тырыштылар. Ләкин аларның явыз ниятләре барып чыкмады.

Социалистик илнең бәхетле, ирекле татар халкы үзенең талантлы улына,атаклы язучысына хөрмәт белән карый, аның иҗатына югары бәя бирә һәм анын кадерле исемен хәтерендә озак саклый. »

Х.Хәйри

-КЛУБ СӘХНӘЛӘРЕНДӘ

Ом
г
3
*
3
си
ЙЗ
§
©
-[·Чч

„ХАФИЗАЛАМ ИРКӘМ" ОБРАЗЛАРЫ

ХАФИЗ

ХАФИЗӘ

АВЫЛ КЫЗЫ СӘГАДӘТ .

МӘРФУГА

СӘРБИ

СИБИ

КӘРИМ

КӘРИМӘ

КУНАК. АВЫЛ КЫЗЫ

БАНКРОТ" ОБРАЗЛАРЫ

СИРАЖЕТДИН

ГӨЛҖИҺАН

ГАЙБӘТЧЕ ХАТЫННАР

мәликә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘДӘН КУРЕНЕШ

ГАРИФӘ

Б А Н К Р О Т“ ОБРАЗЛАРЫ

ҖАМАЛЕТДИН

ДВОРНИК БАБАЙ

АСРАУ КЫЗ — ХӘМДИ

Г. Камал, драматург, прозаик, шагыйрь булу белән генә чикләнеп калмады. Ул карикатурачы, каллиграфист булып та бик күп эшләде.

Г. Тукай белән бергә чыгарган «Яшен» журналында, «Ялт-Йолт» журналында һәм башка газеталарда Йолдыз», «Казан мөхбире») күп санда карикатура бастырды. Аның барлык рәсем, карикатуралары 200 дән артып китә.

Драматург Г. Камал тарафыннан «Яшен» һәм «Ялт-Йолт» журналлары өчен ясалган карикатуралар.

«КАЗАНДА ПЕЧӘН БАЗАРЫ ЧАТЫНДА ПОЛИТИКА МӘҖЛЕСЛӘРЕ»

«Мин сезгә әллә кайчаннан бирле әйтеп киләм бит, Төрек Ягрупага махе бирмәс дип. Менә инде хәзер Төрек Австралияне Македониядән куып чыгарган ди»

«Яшен» № 2



ЫСУЛ КАДИМЧЕ ПИВНОЙДА.

«Ысул җәдид валлаһи хәрам»

«Яшен» №2



«БАЙ БӘТЧӘ» МӘКӘРЬЯДӘН КАЙТКАЧ.

«БАЙ БӘТЧӘ» МӘКӘРЬЯДӘ»

«Яшен» №2



«ЯШЕН» ЖУРНАЛЫНЫҢ 2 НЧЕ НОМЕРЫНЫҢ ТЫШЛЫГЫ

Рәсемдәге текст: «Дипутат «Байбулыйм» дума трибунасында нотык сөйләгәнен төшендә күрә.»



МӘКӘРЬЯДӘН СОҢ БЕЗНЕҢ БАЙЛАР НИ ЭШЛИЛӘР
«Яшен» № 2



«ЗУР» КЕШЕЛӘРНЕҢ РӘСЕМНӘРЕ

«Мәшһүр оратор «Байбулыйм»

«Ялт-Йолт» №3

«Егерменче гасырда тән җәзасы нәсех кылынган заманнарда ысул кадим хәлфәсенең мәктәптә шәкерт тәрбия кылуы»

«Ялт-Иолт» № 3

«Бала. Әти, теге бара торган нәрсәләр ниләр алар?

Атасы. Углым, алар печән чүмәләләре.

Бала. Соң алай булгач, ник аларның аяклары бар?

Атасы. Углым, алар әвәлдәрәк кеше булганнар»

«Ялт-Йолт» № 3

«Мәмдух байның «биржавая» ресторны сәхнәсендә гастрольләре»

«Ялт-Йолт» № 3

«Мөгаллим күз күнендә читкә китәргә урын сорап газета идарәсенә килгәндә»

«Ялт Йолт» № 3

«Мөгаллим яз күнендә авылдан шәһәргә килеп газета идарәсенә кергәндә

«Ялт Йолт» № 3

«ШӘРЫК» КЛУБЫНДА ЛАТО — КОТЕЛЬ УЕННАРЫ

ЫСУЛ КАДИМЧЕЛӘР ТЕАТРЫ

«Бас кызым әпипә, син басмасаң мин басам!»

«Ялт-Йолт» № 4

ИКЕ ХАТЫН БЕРЛӘ ТОРМЫШ

«Биек тауның башыннан
Күренәдер бер авыл,
Хатын өстенә хатын алсаң
Менә шулай була ул.
Авыл җырларыннан»

«Ялт-Йолт № 4

«Купецлар» клубында газета мөхбирләрен тиешле ихтирам илә каршы алдылар»
«Баянылхак».

«Ялт-Йолт» № 4

ЗУР КЕШЕЛӘРНЕҢ РӘСЕМНӘРЕ

«Депутат Нукаев»

•Ялт-Йолт» № 6

«Кем дә кем аллага тәкарепне (якынлыкны) теләсә, мөрид булып аркасын ишаннан камчы илә ярдыртырга тиеш. Һәм саваплы һәм мөҗәрриптер»

«Ялт-Йолт» № 4

ЗУР КЕШЕЛӘРНЕҢ РӘСЕМНӘРЕ

«Депутат Шер-Махутов нотык сөйләр алдыннан»

«Ялт-Йолт № 4»

ЫСУЛ КАДИМЧЕ БУРЕКЧЕ

«ләгыйн»нең театр илә мөхи-
рәбәсе (сугышы)»
«Ләгыйн» абзыйның театр
илә сугышырга хәзерләнүе».
«Ләгыйн» агайның театр ишеге
төбендә сугышуы»

«И ходаем, тагы бер йөзек киярлек тә урын калмады. Ни өчен бу кул бармаклары егерме булмады икән?»

«Ялт-Иолт» № 6

ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗНЕҢ ТӘУСЫЙФЫ
БУЕНЧА МАТУР КЫЗ

«Нәкъ менә шагыйрьләр тәусыйф кылганча булды. Анлар әйткәнчә: Ай күк түгәрәк йөзле, кыйгач кашлы, йолдыз күзле, озын кара чәчле, энҗе тешле, мәрҗән шикелле иренле, аккош муены шикелле муенлы»

«Ялт-Йолт» №7

АВСТРИЯ

Арнаудлык

«Ялт-Иолт» № 6

«Әхмәтҗан абзыйга житмеш ел икмәк черетүе шәрәфенә булак күпере астына салынган ядкар»

«Ялт-Йолт» № 8

«Америка вә Кытай дуслыгы
Америка Кытайны бик ярата»

«Ялт-Йолт» № 8

Хажи абзый урамда хатыны белән йөргәндә»

«Хажи абзый урамда үзе генә йөргәндә».

«Ялт-Йолт» , № 9 >

«Җуан бай. Ата малы баланыкы түгел, иганә иң элек минем улыма тиеш.

Яшь бай. Йортымыз, матбагамыз булса да без фәкыйр, иганә безнең брадәрләремезгә дә бик тиеш.

Икесе бергә. Нишләмәк кирәк, башкаларга быел инде иганә бирерлек акча калмады»

«Ялт Йолт» №9

«Иранда шикәргә бойкот»

«Кешегә сөйләмә, сиңа сер итеп кенә әйтәм, хәзерге заманда «акча өстәп асрауларны кияүгә бирүләр», «балалыкка алып асрап үстергән кызларын яшь хатынлыкка алулар» байлар арасында модага кереп китте»

«Ялт-Йолт» .№ 9

«Интеллигент»

«Мулла»

«Миссионер»

«Мулла вә миссионерның һәр икесенең дошманнары бердер»

«Иң арзанлы, ләкин бик таза фундамент өстенә салынган 50 мең сумлык йорт»

«Ялт-Йолт» №10

(Бу рәсемдә Уфадагы диния идарәсе күрсәтелә)

Г. КАМАЛ

(на татарском языке)

Җаваплы редактор *Г. Кашшаф*

Басарга кул куелды 16ЛY 41 е. Тираж 3070. Басма табак 14. Табакта 38000 хәреф Авт. табак 10,83. Заказ №55. II Ф V 2519. Бәясе 18 сум 50 тиен, Төпләү 1 сум 50 тиен.

Басылды Камиль Якуб исемендәге китап фабрикасында. Казан, Бауман урамы 19. 1941 е.